Мәрьямнең балачагы вә үсмер кыз еллары турында әлегә шушылар билгеле. Моннан соң чит ил чыганаклары белән эш ителәчәк. Хронологик тәртиптә караганда, Мәрьям ханымның исеме беренче тапкыр «Tasvir» («Тасвир») төрек гәзитендәге некрологта калкып чыга. Шулай да без З. Вәлиди Тоганның 1967 елда Төркиядә бастырган һәм 1998 елда Уфада рус теленә тәрҗемә ителеп дөнья күргән истәлекләренә күчәбез.

Зәки Вәлиди Тоган әфәнде, Мәрьям ханымга артык игътибар итмичә, аның исемен ире Али Рыза бәйне искә алуы уңаеннан гына атап уза: «Беренче бөтендөнья сугышы вакытында урысларга әсирлеккә төшкән Али Рыза яшь бохарачылар оештырган хәрби мәктәп җитәкчесе була. Аның белән бергә хәлал җефете, – татар кызы Мәрьям ханым (Казан төрекләреннән танылган мөселман дин эшлеклесе Гобәйдулла Бубиның кызы) була» (Валиди Тоган).

Мәрьям Нигъмәтуллинның, чыннан да, Гобәйдулла Бубиның кызы булуы турындагы ышанычлы нәтиҗәбез әлеге сүзләр һәм некрологта чагылыш тапкан хәбәр нигезендә ясала.

Мәрьям туташ белән Али Рыза бәйнең кайчан гаиләә корулары әлегә билгеле түгел. Төрек гаскәренең йөзбашы (капитан) Али Рыза Сарыкамыштагы уңышсыз һөҗүм аркасында әсирлеккә эләккән була (Bademci A). Русия армиясенең Кавказ фронтында төрекләргә каршы контр-һөҗүм башлавы галәмәт күп төрек хәрбиләренең әсирлеккә төшүенә китергән: сүз 15000 башлап 60000 гә кадәр әсир турында бара. 1914 елның көзендә аларның төп өлеше Сызрань һәм Самара аша уза. 1915 елның 22–28 март көннәрендә генә Самара станциясе аша 66 меңнән артык әсир узган була (Гусева). Самарадан соң әсирләр Кавказга, Украинага, Үзәк Россиягә, Себергә һәм хәтта ерак Маньжуриягә озатылалар (Сибгатуллина: 205).

Беренче җиһан сугышы елларында Русия татарлары төрек хәрби әсирләренә рухи һәм матди ярдәм күрсәткән хәйрия оешмалары булдырганнар (Сибгатуллина: 216). Мондый оешмаларының таралышы гаять киң булган: Әстерхан, Екатеринбург, Казан, Кострома, Мәскәү, Түбән Нов-

город, Оренбург, Пенза, Сембер, Тамбов, Тобольск, Төмән, Уфа, Сарытын (Царицын), Чиләбе, кыскасы, татар яшәгән һәр җирдә диярлек бичара әсирләр үзләренә ярдәм күрсәтергә әзер булган дин һәм тел кардәшләре карамагында булганнар. Нәтиҗәдә алар белән җирле татар халкы арасында элемтәләр җайга салынган һәм хәтта гаиләләр дә барлыкка килгән. Күп кенә төрекләр, татар гореф-гадәтләрен, тормыш рәвешен кабул итеп, татар кала вә авылларында яшәп калуны сайлаганнар (Сибгатуллина: 217).

Югарыда әйтелгәннәрне истә тотканда, Али Рыза белән Мәрьям туташның танышулары сәер түгел. Ул танышу 1917 ел Октябрь революциясеннән соң ук булган дип фараз кылып була. 1917 елда Мәрьям туташ инде 19–20 яшьләренә ирешкән җиткән кыз була. Ул, мөгаен, хәйрия эшчәнлеге белән шөгыльләнгән була һәм әсир төрекләр белән аралаша.

Молла Нафизнең истәлекләренә күрә, Мәрьям туташ Совет власте органнарында да эшләгән яки алар белән хезмәттәшлек иткән: «*... ул большевикларга кушылырга мәҗбүр була һәм үзенә хас зирәклек һәм нык холкы аркасында шул тирәлекнең танылган лидерлары арасына керә. Большевизм юлбашчыларының тар даирәсенә үтеп кереп ул үзенең яңа иптәшләре ягыннан ярдәмгә ирешә*» (Pirnefes Türkistanlı: 363).

Совет оешмасында эшләгән чагында Мәрьям туташ таң калдырырлык бер эш башкара – күпсанлы төрек әсирләрен азат итә. Төрек чыганакларында хәбәр ителгәнчә, әсирләрне азат итү өчен Мәрьям туташ үз өлешенә тигән мирасын – патша заманыннан калган 10000 алтын тәнкәсен совет хөкүмәтенә тапшыра[5]. Бу изге гамәле нәтиҗәсендә 1800 төрек әсире алдында туган илләренә кайтып китү юлы ачыла (Rusya Araştırmaları Enstitüsü). Азат ителгән әсирләрнең берсе булган Али Рыза бәй белән Мәрьям туташ Нигъмәтуллина никахлашалар (Pirnefes Türkistanlı: 364). Хәзерге вакытта яңа гаиләнең кайчан барлыкка килгәне тәгаен генә мәгълүм түгел. Шулай да аның 1918 яки 1919 елда барлыкка килүен фаразлап була. Бу хакта 1921–1922 елларда Әнвәр-паша[6] чирүендә хезмәт иткән Али Рызаның фотосурәте дәлил булып тора (Рәс. 6).

Фотодан аңлашылганча, Төркестан чорында Мәрьям ханым белән Али Рызаның Галия-Севим исемле кызлары булган. Молла Нафизның язуынча, 1923 елда кечкенә Галия-Севим өч яшендә була. Димәк, бала 1920 елда дөньяга килә. Болай булганда, никахлашу тантанасының 1918–1919 елларда үткәрелгәнен тәгаенләп була.

Молла Нафизнең истәлекләреннән күренгәнчә, большевиклар рус булмаган халыкларга, бигрәк тә мөселманнарга карата сәясәтен кискен

---

[5] Ул чактагы 10000 алтын тәңкә хәзерге 800000 АКШ долларына тиң булып чыга.

[6] *Әнвәр-паша* (*Исмәгыйль Әнвәр-паша*, 1881–1922) – Госманлы дәүләтенең хәрби эшлеклесе, сәясәтче; Дөнья сугышы вакытында Госманлы дәүләтенең хәрби министры.

үзгәрткәннән соң, Али Рыза белән Мәрьям ханым ул вакытта мөһим вакыйгалар кичергән Бохарага күчеп китәләр (Pirnefes Türkistanlı: 364).



Рәс. 6. Али Рыза, аның кызы һәм хезмәттәшләре. Әлеге фотосурәт З. Вәлиди Тоганның хатирәләр китабында китерелә.

1920 елның сентяберендә Кызыл Армия «Яшь бохаралылар»ның[7] кораллы милли куәтләре һәм җирле большевиклар ярдәме белән Бохара әмирлеген тар-мар итә. Яшь бохаралылар белән җирле большевикларга Бохарада совет республикасы төзи башларга мөмкинлек ачыла. Бохара Хөкүмәтен тәшкил иткән Революцион Комитет белән Назирләр Шурасы (Комиссарлар Советы) оештырыла, ә октябрьдә Бохара Халык Совет Республикасы (БХСР) барлыкка килүе игълан ителә. БХСРның хәрби назире (комиссары) итеп Габделхәмид Гарифов (1894–1925)[8] билгеләнә. БХСР үзенең барлыкка килүе белән җирле большевикларга һәм Кызыл Армиягә бурычлы булганы өчен Мәскәүгә буйсына торган җепле курчак хәлендәге бер ясалма дәүләт була.




Рәс. 7. Бохара Халык Совет Республикасы. Ачык интернет-чыганаклардан.

---

[7] *«Яшь бохаралылар»* – 1756–1920 елларда яшәгән Бохара әмирлегендә XX йөз башында җәдидчеләр хәрәкәте нигезендә оешкан милли-демократик хәрәкәт вәкилләре.

[8] https://centrasia.org/cnt2.php?st=1510161553 (каралды: 02.05.2020).

Элек хәрби офицер булган Али Рыза БХСРның Кораллы Көчләрен төзүгә җәлеп ителә. Вәлиди Тоган истәлекләренә күрә, 1921 елның мартыннан 1922 елының мартына кадәрге дәвердә хәрби министр вазыйфасын башкарган Арифов[9] Али Рызаны Бохара Хәрби назиренең урынбасары итеп куя һәм аңа Хәрби училище оештыруны тапшыра (Абдуллаев 2009: 201). Али Рызага жандармерия оештыру да йөкләнә (Сибгатуллина: 46). Бу йөздән Али Рызага миралай (полковник) званиесы да бирелә. Тоганның хатирәләренә күрә, ул чакта Али Рыза Мәскәүдә торган Энвер-пашадан килгән хатларны Тоганга тапшырып торган була (Сибгатуллина: 67).

1919 елның язынннан башлап Төркестандагы сәяси, икътисади һәм иҗтимагый вәзгыять бик начарая, чөнки биредә Кызыл Армиянең активлыгы көчәя. Кызылларның максаты мөселманнар яшәгән әлеге территорияләрне тулысынча Мәскәүгә буйсындыру гына булмый – Кремль үзенең Төркестандагы хәрбиләре алдына тагын да зуррак максатлар куя. Кызыл армия, Төркестан җирләреннән һөҗүм башлап, чиктәш Әфганстанны (Абдуллаев 2009: 194) һәм Иранны яулап алырга җыена. Шулай ук Кызыл Армиянең Әзербайҗандагы гаскәре дә, Каспий диңгезенең көньяк-көнбатыш тарафыннан Иранга бәреп керергә тиеш була (Гасанлы).

Большевикларның нинди зур стратегик яуларга әзерләнүләрен истә тотканда, алар Төркестандагы совет режимнарының аз гына булса да мөстәкыйль булуына, әлбәттә, юл куя алмаганнар. Шуңа күрә БХСР хакимияте аңа Мәскәү тарафыннан тагылган сәясәтне уздырырга мәҗбүр булган. Нәтиҗәдә җирле хакимияткә кызыл армеецлар белән бер тарафта эш итәргә туры килә: БХСР җитәкчеләре, аларга буйсынулы җирле кораллы көчләр һәм җирле хакимият органнары Кызыл Армиянең ихтыяҗлары өчен күпләп азык-төлек әзерләүгә керешәләр. Ашлык, фураж, ит һәм башка азык-төлек халыктан көчләп, талап алына да Иранга һөҗүм башлаячак гаскәр туплана барган Әзербайҗанга, озатыла тора (Абдуллаев 2009: 182).

Бу хәлләр җирле халыкны колониаль талауга әйләнә. Төркестан белән БХСР халкы җирле хакимиятнең химаясе астында кызылларның талауларын, мыскыл итүләрен үз җилкәләрендә татый, куркыныч дәрәҗәдә хәерчеләнә башлый. Бу вәзгыятьнең никадәр куркыныч нәтиҗәләргә китерә алуын яхшы аңлаган БХСР Халык Комиссарлары Советы рәисе Ф. Хуҗаев[10] 1921 елның җәендә В. Ленин исеменә депеша юллый. Анда: «Республикада урыс кораллы отрядлары ярдәмендә башкарылган ит разверсткасы халык массаларында урысларга карата, һәм, аерым алганда Кызыл Армиягә карата нәфрәт уятты», диелә (Абдуллаев 2009: 182).

---

[9] https://centrasia.org/cnt2.php?st=1510161553 (каралды: 01.05.2020).

[10] *Фәйзулла Хуҗаев* (*Гобәйдулл углы Фәйзулла Хуҗаев*, 1896–1938) – БХСРның илбашы (1920–1924), 1925–1937 елларда Үзбәк ССР белән идарә итә; 1938 елда үлем җәзасына дучар ителә (Арапов).

Моннан тыш, кызылармеецлар, үз ихтыяҗлары өчен мәктәп, мәчет һәм башка изге урыннарны һич ихтирам йөзе күрсәтмәстән басып алып, аларны казарма, склад, ат абзары итеп кулланалар. Кораллы килмешәкләр үзләрен хуҗалар сыман тотып, аз санлы агач йортларны утынга сүтәләр, борынгы мәчет-мәдрәсәләрне мәсхәрә кылалар һәм шул сәбәбле җирле халыкта тагын да кискен ризасызлык, ачулану һәм ярсу хисләре уяталар. Нәтиҗәдә җирле хакимият тә, кызыллар да халык күзендә мәрхәмәтсез талаучылар һәм динне мәсхәрәләүчеләр буларак кабул итә башлый (Абдуллаев 2009). Җирле халыкта илбасарларга каршы дөрләп кабынган ачы нәфрәт стихияле милли-азатлык хәрәкәтенә әверелә. БХСРда һәм Төркестанда кызылларга каршы аякланулар башлана, халык, кулына корал алып, җаны вә малы, дине вә иманы өчен восстание башлый. Совет тарих фәнендә бу хәрәкәт начар мәгънәле басмачылык (юлбасарлык) термины белән атала.

Шул киренке көннәрдә, 1921 елның октябрь ахырында [2] яки, Вәлиди Тоган хәбәренә күрә, декабрь аеның 20 сендә (Сибгатуллина: 69), Әнвәр-паша кисәк кенә Бохарага килеп төшә һәм биредәге вәзгыять белән таныша башлый. З. Вәлиди Тоган Әнвәр-пашаның Бохарага юл тотуының сәбәпләре турында болай дип яза: «Төркестандагы эшчәнлеге белән бәйле булган соңгы карарларын ул биредә, Бохарага килеп төшкәннән соң, кабул итә. Урысларның аңа Җәмал-паша белән күререшгә мөмкинлек бирүдән баш тартулары[11] әлеге адымга этәргеч була. Өстәвенә консул Юренев[12] Әнвәр-пашаның үзенә карата яшеренеп тормастан янаган була» (Сибгатуллина: 76).

Нәтиҗәдә, Әнвәр-паша Төркестанда Советларга каршы башланган халык хәрәкәтенә кушылырга карар кыла, чөнки бу адым аңа: «*Бөтен мөселманнарны берләштергән (панисламистик) дәүләт яки дәүләтләр берләшмәсе булдыру турындагы планнарын тормышка ашырырга форсат бирә. Әлеге берләшмәнең башында ул, әлбәттә, үзенең яраткан һәм соңгы көненә кадәр җанатары булган Төркиясен күрә. Гомере өзелгәнче Әнвәр-паша үзенең Истанбул белән Әнкарадагы тарафтарлары белән араны өзми һәм ватанына җиңүче баларак тантаналы кайтуы турында хыялланган була*» (Абдуллаев).

Шул ук вакытта диярлек Әнвәр-пашаның Урта Азиядә Совет хакимиятен бәреп төшерерүгә юнәлтелгән планнарынна БХСР югары дәрәҗәле вәкилләре дә кушылырга ризалык белдерә. Андыйлар арасында Мәрьям ханымның ире Али Рыза, Г. Арифов һәм БХСР илбашы Ф. Хуҗаев та булалар.

---

[11] *Җәмал-паша* (1872–1922) – госманлы хәрбие, сәясәт эшлеклесе, большевиклар белән бергәлектә Һиндстанда инглизләргә каршы көрәш идеясен алга сөргән (Валиди Тоган: 58).

[12] *Юренев* (Константин Константинович Юренёв (Кротовский), 1888–1938) – 1921 елның 16 маеннан 1922 елның 1 февраленә кадәр РСФСРның Бохарадагы вәкиле.

Әнвәр-паша җитәкләгән милли-азатлык сугышы төркестанлыларның җиңелүе белән тәмамлана. Ул үзе 1922 елның 4 августында кызыллар белән бәрелештә шәһит була. Әнвәр-пашаның каһарманнарча һәлак булуы турындагы шәһадәтнамәне Али Рыза үз кулы белән яза. Документта пашаның кайчан, кайда һәм нинди шартларда шәһит булуы хәбәр ителә.

Молла Нафиз язмаларына күрә Әнвәр-паша кулы астында Али Рыза Бохара оператив армиясенең гаскәр башы була, ә паша шәһит булганнан соң Көньяк фронт белән җитәкчелек итә (Pirnefes Türkistanlı: 341). Ул Керки белән Әфганстан арасындагы чүлләрдә кызыллар белән аяусыз сугыш алып барган чакта аның янында гаиләсе – хәрби госпитальдә шәфкать туташы булып эшләгән Мәрьям ханым һәм кечкенә кызы Галия-Севим – дә була.

Әнвәр-паша армиясенең калдыклары тулаем тар-мар ителгәч, 1923 елда Али Рыза гаиләсе белән Әфганстанга күчеп китә. Вәлиди Тоган истәлекләренә күрә, 1923 елның июнь аенда Әфганстанда Кабул юлындагы Бәдбаһ атлы бер урында ул очраклы рәвештә Али Рыза белән очраша. Али Рыза белән Мәрьям ханым Әфганстаннан Иран аша Төркиягә юл тоткан булалар (Валиди Тоган: 181). Иранда аларның юллары Мәшһәд шәһәренә төшә. Биредә алар күпмедер вакыт Төркия визасын көтеп, түләүле фатирда яшәгәннәр. Мәшһәдтә Али Рыза гаиләсенә Төркестаннан качып киткән башка көрәштәшләре дә кушылалар (Pirnefes Türkistanlı: 341).

1923 елның 24 октябрендә Мәшһәдтәге Төркия консуллыгында мосафирларга визалар бирелә. Декабрьнең 4 ндә Али Рыза белән Мәрьям ханым һәм тагын уникегә якын кеше Мәшһәдтән Төркиягә таба юлга чыгалар[13].

Молла Нафиз бу мөсафирларның юлда күргән-кичергәннәрен үзенең истәлекләрендә язып калдырган. Сәфәр гаять авыр шартларда кичкән: аты булганы атына атланып барган, булмаганнары – җәяү атлаган. Бу көннәрдә Молла Нафиз Мәрьям ханымның сокландырырык чыдамлылыгы һәм ир-атларга үрнәк итеп куярга мөмкин булган какшамас холкына хәйран калып, аның турындагы язмаларны көндәлегенә теркәп куя.

Декабрьнең 15 ндә кечкенә кәрван Каспий диңгезенең көньяк-көнчыгыш «почмагы» янында урнашкан Эстәрабад каласына барып җитә (хәзерге вакытта Гөргән шәһәре). Мәрьям ханымга багышланган бүлекне Молла Нафиз нәкъ шушы шәһәрдә язган.

Сәфәр ахырына якынлашкан көннәрдә Али Рыза аркасында мөһаҗирләр төркеме чак кына харап булмый: Иранның Төньяк фронты баш куманданы Әхмәт Казак Хан «Төрек офицерлары» өчен тантаналы кичке аш үткәрә. Чарага Эстерабад шәһәренең вәлие, иминлек хезмәте мөдире һәм хәтта совет консулы чакырылган була. Кунаклар төрек офицерларының Русиядә әсир чакларында күргәннәре турында сөйләүләрен

[13] Әлеге төркемдә мәгърифәтче әдип, нашир Фатих Кәриминең бертуган энесе Гариф Кәрими дә була (1892–1934) дә була.

үтенәләр. Мактанырга хәвәс булган Али Рыза кызып китеп үзенең әсирлеккә төшүе турында гына түгел, Бохарада хезмәт иткән көннәрен дә, Әнвәр-паша гаскәрендә большевикларга каршы сугышта катнашуын да, Көньяк фронт белән командалык итүче буларак, кызылларга каршы ничек көрәшкәнен сөйләп ата.

Али Рызаны шаккатып тыңлап утырган совет консулы шундук җирле хакимият органнарына мөрәҗәгать итеп, әлеге офицерларның ватаннарына кайтып баручы мосафирлар түгел, ә Совет властенә каршы сугышкан гыйсьянчылар булуын дәгъвалый һәм аларның кулга алынып, советларга тапшырылуларын таләп итә. Нәтиҗәдә, мөһаҗирләр төркеме Әхмәт Казак Хан тарафыннан аларга бирелгән йортта ук сак астына алына.

Бу хәлнең куркыныч нәтиҗәләргә китерәчәген аңлаган Молла Нафиз Төркиянең Тәһрандагы бөек илчесе Мөхитдин-пашага телеграмма суга һәм төрек офицерларының нинди бәлагә тарыганнары турында хәбәр итә. Мөхитдин-паша дәшми калмый – мосафирларны тоткыннар халәтеннән «хөрмәтле кунаклар» хәленә күчерәләр. Әмма әлеге хәтәр вакыйга арка-сында Төркиягә юл ябыла. Нәтиҗәдә 1924 елны юлчыларга Эстәрабадта каршы алырга туры килә. Гыйнварның 20 сендә алар Тәһранга юл тоталар һәм дүрт көннән төркем Төркиянең Ирандагы бөек илчесе белән күрешә.

Мөхетдин-паша аларга булдыра алган кадәр ярдәм итә: мосафирларга акчалата ярдәмне рәсми документлар аша үткәрергә хакы булмаганга күрә, ул үзенең токымлы атын һәм фаэтон арбасын сатып, шуннан кергән 300[14] түмән күләмендәге табышны юлчыларга тапшыра. Бу акча аларга Төркия чигенә кадәр яки, ким дигәндә, Тәһраннан 500 чакрым чамасы төньяк-көнбатышка таба урнашкан Тәбриз шәһәренә кадәр барып җитәргә мөмкинлек бирә. Шул 300 нең 75 түмәнен киң күңелле Мөхитдин-паша Али Рызаның гаиләсенә үзенең шәхси бүләге буларак тапшыра.



Рәс. 8. Мөхитдин-паша Акъйөз (1870–1940) 1922–1925 елларда Төркия Җөмһүриятенең Ирандагы бөек илчесе.

1924 елның 5 февралендә Молла Нафиз Али Рызаның гаиләсеннән аерыла һәм башка юлдашлары белән Төркиягә юл тота. Рызалар гаиләсе, кышкы юлларда балага зыян тиюеннән куркып, Тәһранда язга кадәр калып торырга карар кыла. Али Рыза белән Мәрьям ханым Әнкарага 1924

[14] *Түмән* – 1825–1932 елларда Фарсыстанда кулланылышта булган валютаның атамасы.

елның язында килеп җитәләр: «*Аннан соң, Төркиядә аның белән күп тапкырлар очрашканым булды. Алар Әнкарада Фәүзи-паша биргән йорт-та, вафатына кадәр яшәделәр. Али Рыза-бәй [Фәүзи] паша даирәсенә кергәннән соң, аның барлык маҗараларының шаһиты булды*» (Валиди Тоган: 181). Вәлиди Тоган хатирәләреннән Али Рыза белән Мәрьям ханымның Фәүзи-паша[15] биргән йортта аның вафатына кадәр, ягъни 1950 елга кадәр яшәгән булулары аңлашыла.

Фәүзи-пашаның ярдәме белән Али Рыза Төркия хәрби көчләрендә хезмәт итүен дәвам итә (Bademci: 15). Бу елларда Мәрьям ханымның ничек көн күрүе турында, кызы Галия-Севимнең язмышы турында фикер йөртүе кыен, чөнки Тоган истәлекләрендә алар хакында нинди дә булса өстәмә мәгълүмат юк. Бу хакта хәбәр бирерлек башка чыганаклар да әлегә табылмады. Шулай да Төркиядә яшәүче татар егете Ильяс Мифтаховның ярдәме белән Али Рыза әфәнденең гаиләсенә кагылышлы бер документка ия булдык. Документ Әнкараның Калаба районында яшәүче Али Рыза әфәнде белән аның тормыш иптәше Мәрьям ханымга 716 номерлы канун нигезендә Истанбулда торыр йорт бирелүе турында хәбәр итә. Төркиянең Милли архивлар министрлыгының архивында 30–18–1–2 номеры белән сакланган әлеге документка мөһер 1945 елның 12 нояберендә сугылган. Димәк, 1945 елның ахырында Мәрьям ханым белән аның иренең Истанбулга күчеп китүләре турында шикләнмичә сүз йөртеп була (Рәс. 9).

Моннан соң Мәрьям ханымның Төркиядәге эзләре югала кебек. Әмма югарыда китерелгән гәзит парчасына игътибар итсәк, өстәмә мәгълүмат бөртекләрен тергезеп була. Мәрьям ханымның вафаты уңае белән басылган бу мәрасим мәкаләсендә «*Уфалы Гобәйдулла әфәнде* (*Ufalı Ubeydullah Efendi*)» дип аның атасының һәм «*Али Атмаҗа* (*Ali Atmaca*)» дип иренең исемнәре искә алына. Мәрьям ханым үзе дә Атмаҗа фамилиясе белән телгә алына. «*Ватанпарвәр бер төрек хатыны вафат булды*» (*Vatanperver Bir Türk Kadını Vefat Etti*) дип аталган бу некролог «Tasvir» («Тасвир») гәзитендә Мәрьям ханымның фотосурәте белән бергә китерелгән. Кызганыч, фотосурәтнең сыйфаты начар. Эзләнә торгач, интернетта Мәрьям ханымның әлеге фотосурәтенең сыйфатлы нөсхәсе табылды.

---

[15] *Фәүзи-паша* (1876–1950) – Госманлы һәм Төркия хәрби эшлеклесе, 1921–1922 елларда Төркиянең премьер-министры Ататөрекнең дусты һәм көрәштәше; 1924–1944 елларда Төркия Хәрби куәтләренең Генераль штабы рәисе.



TASVİR

**Vatanperver bir Türk gadını vefat etti**

Merhum Meryem Atmaca

Vatanperver kadınlarımızdan biri daha, dün öğleye doğru hayata gözlerini yummuştur. Bu, Ufalı Übeydullah efendinin kızı ve sabık Rumiye başkonsolos vekili yüzbaşı Ali Rızanın refikası Meryem Atmaca hanımdır.

Çarlığın çökmesini müteakip ... kistanda başlıyan milli hareketin seyrini bilenler Meryem Atmacanın ismine yabancı değillerdir. Kendisi, burada bilfiil harekâta iştirak etmiştir. Onun bu vatana asıl büyük yardımı, birinci cihan harbinde Ruslara esir düşüp Sibiryaya sürülen ve Çarlığın inhilâline rağmen anavatana dönemiyen 1800 subay ve eri, milli mücadelenin en lüzumlu anında kendi kesesinden 10 bin altın sarfetmek suretile Anadoluya ...

**...la iç ...arttı**

...rulan ...olunuz!„

... müfrit hareketler... teşvik edecek bir ma... nektedir. Filhakika, ... karşısında ve taraf...

... bir kamuoyun he... bir surette kraliyeti ... eceği, solcular tara... takdir edilmektedir.

**... demeci**

(... 1 inci sahifede)

... nek için Rusların ... gözümüzde

...RDUSU KUVVETİ... ...AZA EDECEK

(A.A.) — Ameri... ...leketlerde ... müddetçe ... muhafaza eder bir ... bulunmak niyetinde...

... Eisenhower, Spaatz, Patterson ve dış ... yrnes'ün iştirâkile ... askeri komisyonu... ... esnasında ya... ... mâna bu...

**Türk Sovye...**

(Baş tarafı 1 inci s...)

misline çıkarılmıştır. ... tank mütahassısı Mareşal ... yan, Tebrizde iki veya 3 ... mıştır.

RUSLARIN TAHŞİDAT... LERİ ANKARADA SÜ... KARŞILANDI

Ankara 14 — Sovyet ... veya Rus askerle... halinde bulundukları hakk... berler burada sükûnet ve ... lılıkla karşılanmıştır. Bu ... herhangi resmî bir malû... ğine dair bir haber alı... Herkeste kararını vermiş ... hâs bir sükûnet ve raha... hede edilmektedir.

RUSLARIN YAKINDA ... DEN TALEPLERDE B... SI BEKLENİYO...

Vaşington ... büyük elçisi ... Âlâ, güney doğu istikam... rana doğru ilerliyen Rus ... İrana karşı olduğu kadar ... Türkiyeye karşı da ... muhtemel olduğunu söyl...

Elçi: «İrana Rus takvi... gönderilmesini beklemiyo... miş ve şunları ilâve etmiş ... yet öyle bir şekil almıştı ... İranda bir sinir harbi ba... olamaz.»

Рәс. 9. Мәрьям ханым Атмаҗага багышланган мәрасим мәкаләсе басылган гәзит сәхифәсенең бер парчасы. https://onedio.com/haber/ruslara-esir-dusen-1800-askeri-babasindan-kalma-altinlarla-kurtaran-kahraman-turk-kadini-meryem-atmaca-867501 (каралды: 18.03.2022).




Рәс. 10. Мәрьям ханым Атмаҗа (Нигъмәтуллина / Бубинскаяның) әлегә табылган бердәнбер фотосурәте. https://www.pinterest.ru/pin/448671181619674026/?nic_v1=1aoqdO%2Bg95dDP1KHy3jSozLZ9a6kiz98k4G1SS6ypOTjddpY5yvZb2T6RRyYCEv7oK (каралды: 18.03.2022).

Фотосурәттә Мәрьям ханымның үз кулы белән язган язуы сакланган:

*Meryem Atmaca*
*1941*
سنه سنده آلدرمش رسمم
*(Мәрьям Атмаҗа 1941 сәнәсендә алдырмыш рәсемем)*

Атмаҗа дигән фамилия Али Рызаның 1935 елда хөкүмәт тарафыннан гражданнарны аурупадагыча фамилияләштерү максаты белән үткәрелгән реформа дәвамында алган фамилиясе булып чыга.

Рамазан Балҗы әфәнденең каләме белән язылып, Мәрьям ханымны искә алган мәкалә интернетка җибәрелгәннән соң, виртуаль галәмдә атасыннан калган күләмле мирасны төрек гаскәриләрен әсирлектән азат итүгә тотып бетергән каһарман төрек хатынын сурәтләгән кыска видеофильмнар пәйда була. Әмма ул видеосюжетлардан әлеге фидакарь ханымның кайсы халык вәкиле булуы, нинди газаплар кичерүе булуы турында бер генә җөмлә дә әйтелми.




Рәс. 11. Мәрьям ханымның «кабер ташы». Ачык интернет-чыганаклардан.

Ниһаять, Мәрьям ханымның ни заман вафат булуы турында да берике сүз әйтергә, әлбәттә, кирәк. Хәзергә бу дата билгеле түгел. Әйе, интернетта йөргән фильмнарның берсендә аның бу дөньядан киткән вакыты 1926 ел дип күрсәтелә. Мәсәлән, бу дата, имештер, аның кабер ташында сугылган (Рәс. 11). Димәк, Мәрьям ханым җир йөзендә нибары 36 ел яшәгән булып чыга. Болай булганда әлеге мәсьәлә хәл ителгән була кебек. Әмма, чынлыкта алай түгел.

Мәсәлән, әлеге дата, ягъни 1926 ел, хакыйкатькә туры киләме? дигән сорау туа. Беренчедән, югарыда китерелгән фотографиянең 1941 елда төшерелгән булуы үзендә үк язылган. Икенчедән, фотосурәттә «рәсемем» диелгән. Сүзне бу шәкелдә фотографиядә сурәтләнгән кеше үзе генә яза ала булса кирәк. Болай булганда, фильмны төшерүчеләр ялгышалар түгелме икән? Әллә кабер ташын куючылар ялгышалармы? Ни өчен кабер ташында кешенең туган-үлгән еллары гына күрсәтелгән дә, ни өчен, һич югында, вафат булган көне-ае күрсәтелмәгән? Болар сәер булып тоела.

Мәсьәләгә ачыклык кертер өчен баягы «Tasvir» («Тасвир») гәзитеннән калган парчаны җентекләбрәк тикшерердек. Башлап җибәрер өчен биредә ул мәкаләнең төрекчә күчермәсен китерәбез:

*Vatanperver Bir Türk Kadını Vefat Etti*

*Vatanperver kadınlarımızdan biri daha, dün öğleye doğru hayata gözlerini yummuştur. Bu Ufalı Übeydullah efendinin kızı ve sabık Rumiye başkonsolos vekili yüzbaşı Ali Rızanın refikası Meryem Atmaca hanımdır.*

*Çarlığın çökmesi* [сүз укылмый] *Türkistanda başlıyan milli hareketin seyrini bilenler Meryem Atmacanın ismine yabancı degildirler. Kendisi, burada bilfiil harekata ıştırak etmiştir. Onun bu vatana asıl büyük yardımı, birinci cihan harbinde Ruslara esir düşüp Sibiryaya sürülen ve Çarlığın intihaline rağmen anavatana dönemiyen 1800 subay ve erii milli mücadelenin en lüzümlü anında kendi kesesinden 10 bin altın sarfetmek suretiyle Anadolu* [текст өзелә]...

Тәрҗемәсе:

*Ватанпәрвәр хатыннарыбызның тагын берсе, кичә өйлә җитәрәк хәяткә күзләрен йомган. Бу Уфалы Гобәйдулла әфәнденең кызы һәм элекке Румия башконсулы вәкиле йөзбашы Али Рызаның тормыш иптәше Мәрьям ханым Атмаҗадыр.*

*Самодержавие бетеп [сүз укылмый] Төркестанда башланган милли хәрәкәтнең агышын белгәннәр өчен Мәрьям Атмаҗаның исеме ят бер исем түгел. Андагы хәрәкәттә ул турыдан-туры катнашкан. Аның бу ватанга чын зур ярдәме, Беренче бөтендөнья сугышында русларга әсир төшеп Себергә сөрелгән һәм, самодержавиенең бетүенә карамастан, ана ватаннарына кире кайта алмаган 1800 офицер һәм солдат милли көрәшнең иң кирәкле чагында үз кесәсеннән 10 мең алтын акча сарфы итеп, Анадолу [текст өзелә]...*

Һәрхәлдә әлеге мәрасим мәкаләсе Мәрьям ханымның вафат иткән көннең иртәгесендә язылган булып чыга. Әмма гәзитнең чыккан датасы күренми. Өстәвенә, мәрасим мәкаләсенең тексты тулы түгел – аның астагы өлеше ертылып атылган. Мәкаләнең як-якларында башка язмаларның өлешләре бар, тик алар да тулы түгел – калган өлешләре вертикаль юнәлештә ертылып атылганнар. Бу йөздән ул язмаларның эчтәлеген тулысынча аңлау мөмкин түгел – аерым сүзләр, сүзтезмәләр генә укыла. Нәтиҗәдә, шул өзекләрне өйрәнеп, алардан мөмкин булган кадәр мәгълүмат алудан кала башка чара юк.

Бу эшне башкарып чыкканнан соң, Мәрьям Атмаҗаның вафаты турындагы мәкаләнең 1945 елның көзе белән 1946 алның язы арасында, ягъни ике ил арасындагы сәяси вәзгыятьнең киеренке чагында чыккан булуы ачыкланды. Мәсәлән, Төркия белән Советлар Берлеге чигендә аеруча киеренке хәлләр 1946 елның мартында булып ала. Бу хакта «Tanin» («Танин») гәзитенең 1946 елның 14 мартында чыккан саны хәбәр бирә (Uzman: 123).

Дөрес, 1920 елларның икенче яртысында да Төркия белән Советлар Берлеге арасында сәяси-дипломатик сәхнәсендә тартышулар булган. Болай булганда, Мәрьям ханымның 1926 елда вафат булуы мөмкин нәрсә. Әмма Мәрьям ханым 1926 елда вафат иткән булса, аның турыдагы мәрасим мәкаләсе латин язуында түгел, гарәп язуында басылган булыр иде, чөнки гарәп язуыннан латин язуына күчү турындагы карар Төркиядә 1928 елның ноябрь аенда гына кабул ителә (Яфарова). Латин язуына күчү шуннан соң гына башлана. Димәк, 1926 елда Мәрьям ханым исән булган.

Тагын бер дәлилебез фотосурәттәге язуга бәйле. Аны исәпкә алсак, Мәрьям ханымның 1941 елда әле исән булганын танырга мәҗбүр булабыз.

Мәрьям ханымның 1926 елда вафат булмавы турындагы өченче дәлилебез аның фамилиясе белән бәйле. Чыннан да, Төркиядә фамилияләр 1934 елда гына кертелә башлый. Болай булганда 1926 елда вафат булган кешенең кабер ташында фамилия язылмас иде.

Югарыда китерелгән мәгълүматны истә тотканда, Мәрьям ханымның 1945 яки 1946 елның март аенда вафат булуы хакыйкатькә туры килә булса кирәк.

Ниһаять, Мәрьям ханым турында Молла Нафизның калдырган хатирәләре турында бер-ике сүз әйтергә кирәк. Молла Нафиз Төркестанда большевиклар явына каршы 1921–1922 елларда сугыш алып барган Әнвәр-пашаның көрәштәше һәм аның гаскәрендә мөхәбәрат[16] мөдире булып хезмәт иткән кеше. Ул шулай ук Мирза Пирнәфәс (Mirza Pirnefes) һәм Нафиз Түркәр-бәй (Nâfiz Türker Bey) исемнәре белән дә мәгълүм булган. Молла Нафиз үзеннән соң хатирәләр калдырган. Аның бу язмалары Төркиядә 2010 елда Али Бадәмҗе тарафыннан әзерләнеп, *«Sarıklı Basmacı»* (Чалмалы басмачы) исемле китап буларак дөнья күрә. Әлеге шактый

[16] *Мөхәбәрат* – разведка.

күләмле хатирәләрдә Молла Нафиз Мәрьям ханымны берничә мәртәбә искә ала һәм бу каһарман ханымның фидакарьлегенә, үз-үзен аямыйча милли азатлык өчен көрәшүенә соклануын яшерми. Бу йөздән, Молла Нафиз үзенең хатирәләрендә Мәрьям ханымга аерым бер бүлек багышлауны үзенең бурычы дип санаган. Бу дөньядан 1975 елда киткән Молла Нафизнең хатирәләре хәзерге вакытта Мәрьям ханым турындагы бердәнбер саллы документаль чыганак булып тора. Бу чыганактан әлегә кадәр мәгълүм булмаган каһарман татар хытынының үзе турында һәм аның кырыс язмышының кайбер сәхифәләре турында берникадәр мәгълүмат алып була.

Мәгърифәтче Бубилар кебек зыялы нәселнең әлегә кадәр билгесез булган бер каһарман татар хатынының язмышы турындагы кыска гына хәбәребез әлегә шуннан гыйбарәт. Әгәр бу юлларның авторы Муса әфәнде Бигиев хакында мәгълүмат вә хәбәрләр туплау максаты белән Әнкарага барып чыкмаса, ул кадәре дә булмас иде. Бу башкаланың иң зур китап кибетләренең берсендә тикшеренүләр өчен үземә китаплар сайлап йөргән чакта, әлеге мәкалә авторының кулына югарыда телгә алынган «Sarıklı Basmacı» да керде. Китап 1920 еллар башында Төркестандагы басмачылар хәрәкәте турында һәм аны җитәкләгән Әнвәр-паша турында булып чыкты. Болай булганда бу китапта Муса әфәнде дә телгә алынырга мөмкин иде, чөнки шул ук вакытта ул да Төркестанда кат-кат булган, андагы сәяси-иҗтимагый вәзгыятьтә катнашкан. Шундый уйлар белән әсәрнең ахырында урнашкан шәхесләр исемлеге карап чыгылды. Әмма Муса әфәнденең исеме китапта юк булып чыкты. Моннан соң ни кылырга кала? Китапны киштәгә кире куй да, башкасына сузыл... Әмма әнә шундый мизгелләрдә кешенең кулын тәкъдир йөртәме икән, насыйп сәгатеме, әллә Аллаһ Тәгалә үземе? Китапның эчтәлеген карап чыгарга булдык. Анда да игътибарымны җәлеп итәрлек нәрсә күренмәде кебек, әмма карашыбыз кисәк кенә *Meryem hanım* дип аталган сүзләргә төбәлде. Игътибарны үзенә нигә нәкъ менә шушы җөмлә җәлеп итте икән? Монысын аек акыл белән аңлатып булмый, әлбәттә. Бу мизгелдә Муса әфәнденең эзләреннән йөргәндә күп мәртәбә кичерелгән могъҗизави хәлләрнең берсе вакыйг булды, һәрхәлдә. Шул бүлекне ачып, йөгертеп кенә карый башлавыбыз булды, шундук «*Kuzey Asya Türklerinin fedakâr Ayşesi...*», ягъни *Төньяк Азиянең фидакяр Гайшәсе* дигән сүзләргә юлыктык. Көн кебек ачык – бу бүлек ханым-милләттәшебезнең берсе турында иде... Мәрьям ханым Буби исеменең милли тарихыбыз сәхифәләренә кайтуының насыйп сәгате әнә шул минутларда җитте.

## ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ МАТЕРИАЛЛАР

Абдуллаев К. Смерть «Летучего голландца Востока». https://vladislavvolkov.livejournal.com/39444.html (каралды: 01.05.2020).

Арапов А.В. «Мы не войдем в историю…!?»: к политической биография Файзуллы Ходжаева (1896–1938). http://www.alexarapov.narod.ru /article17.html (каралды: 05.06.2021).

Гасанлы Дж. «Иранская эпопея большевиков» и углубление конфликта на Южном побережье Каспия (1920–1921 гг.) // Кавказ & глобализация. 2012. Т. 6, Вып. 1. С. 137–166.

Махмутова А. Габдулла Буби (1871–1922). https://tatarlarneftekama.blogspot.com/2012/09/1871-1922.html (каралды: 03.12.2019).

Мәктәб-и Фөнүн-и Мөлкия. https://islamansiklopedisi.org.tr/mekteb-i-mulkiyye (каралды: 26.04.2020).

Валиди Тоган З. Воспоминания: Книга 2. Уфа: Китап, 1998.

Хабутдинов А. Мусульманка как учитель и судья: Мухлиса Буби (1869–1937). http://idmedina.ru/books/history_culture/?4645 (каралды: 27.01.2022).

Bademci A. Türkistan'da Enver Paşa'nın Umumî Muhaberat Müdürü Molla Nâfiz'in Hâtıraları. Sarıklı Basmacı. İstanbul: Ötüken Neşriyat A.Ş., 2015.

Balcı R. Meryem Atmaça Kimdir? O Bir Kahraman Türk Kadınıdır. https://www.haberasi.com/meryem-atmaca-kimdir-ruslarin-elinde-bulunan-1800-turk-askerini-altinlarini-vererek-kurtaran-kahraman-turk-kadinidir/405/ (каралды: 07.05.2020).

Rusya Araştırmaları Enstitüsü. https://twitter.com/rusencenter/status/1172663819602034688 (каралды: 02.05.2020).

Pirnefes Türkistanlı M. Enver Paşadan Sonra Doğu Buhara // Bademci A. Türkistan'da Enver Paşa'nın Umumî Muhaberat Müdürü Molla Nâfiz'in Hâtıraları. Sarıklı Basmacı. İstanbul: Ötüken Neşriyat A.Ş., 2015. S. 33–393.

Uzman N. II. Dünya Savaşı Sonrasında Sovyet Talepleri ve Türkiye'nin Tepkisi // Akademik Bakış. 2018. Cilt 11. Sayı 22. S. 117–142.

## ФӘННИ ӘДӘБИЯТ

Абдуллаев К. От Синьцзяна до Хорасана. Из истории среднеазиатской эмиграции XX века. Душанбе: Ирфон, 2009.

Гусева Ю.Н. Турецкие военнопленные Первой мировой войны в Самарской губернии // Новый исторический вестникъ. 2016. № 2 (48). С. 97–112.

Махмутова А.Х. Лишь тебе, народ, служенье! (История татарского просветительства в судьбах династии Нигматуллиных-Буби). Казань: Магариф, 2003.

Махмутова А. Габдулла Буби (1871–1922) // Татарские интеллектуалы: исторические портреты / Сост. Р. Мухаметшин. 2-е изд. Казань: Магариф, 2005. С. 172–188.

Сибгатуллина А.Т. Контакты тюрок-мусульман Российской и Османской империй на рубеже XIX–XX вв. М.: Институт востоковедения РАН, 2010.

Яфарова З.Г. Реформа турецкого языка и ее отражение на страницах журнала «Хаят» (1926–1929) // Вестник СПбГУ. 2015. Сер. 13. Вып. 3. С. 61–67.

**Автор турында белешмә**: Хәйретдинов Айдар Гарифетдин улы – фәлсәфә фәннәре кандидаты, диннәр тарихы һәм иҗтимагый фикер бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре, Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты (420111, Батурин ур., 7А, Казан, Россия Федерациясе); khaidar67@mail.ru

*Редакциягә керде 18.03.2022* *Кабул ителде 22.04.2022*

# МАРЬЯМ ХАНЫМ: ЗАБЫТАЯ ГЕРОИНЯ ДИНАСТИИ БУБИ

***А.Г. Хайрутдинов***

*Институт истории им. Ш. Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*khaidar67@mail.ru*

Статья посвящена Марьям ханым Нигматуллиной-Буби – забытой представительнице знаменитой династии татарских просветителей Буби. В 1917–1920 годах М. Буби участвовала в национально-освободительном движении татар во внутренней России, затем работала в советских госучреждениях и, воспользовавшись этим, добилась освобождения 1800 турецких военнопленных. Позже вышла замуж за одного из них по имени Али Рыза и вместе с ним приняла участие в национально-освободительном движении народов Туркестана против большевистской власти. В статье предпринимается попытка выделения основных этапов жизненного пути М. Буби. В татарскую историографию впервые вводится биографический материал о жизни этой женщины.

**Ключевые слова:** Марьям Бубинская, Бухарская Народная Советская Республика, Туркестан, басмачество, татарская эмиграция, Энвер-паша, Молла Нафиз, Заки Валиди Тоган.

**Для цитирования:** Хайрутдинов А.Г. Мәрьям ханым: Бубилар нәселенең онытылган каһарманы // Историческая этнология. 2022. Т. 7, № 1. С. 77–99. https://doi.org/10.22378/he.2022-7-1.77-99

**Сведения об авторе:** Хайрутдинов Айдар Гарифутдинович – кандидат философских наук, старший научный сотрудник отдела истории религий и общественной мысли Института истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан (420111, ул. Батурина, 7А, Казань, Российская Федерация); khaidar67@mail.ru

*Поступила 18.03.2022* *Принята к публикации 22.04.2022*

# MARYAM BUBI: THE FORGOTTEN HERO OF THE BUBI DYNASTY

***A.G. Khairutdinov***
*Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*khaidar67@mail.ru*

The article is devoted to Maryam Bubi, a representative of the famous Bubi dynasty – enlighteners and outstanding figures of Tatar education. Her name has remained unknown until now. In the period from 1917–1920, Maryam Bubi was a participant of the Tatar Soviet nation-building in inner Russia, and then took a direct part in the national liberation movement of the peoples of Turkestan against the Bolshevik occupation. Together with her husband Ali Ryza, she fought in the ranks of Enver Pasha's army. The article attempts to reconstruct the main stages of Maryam Bubi's life path. The biographical material concerning the life of M. Nigmatullina was collected during the study of little-known and unknown sources and facts to Tatar historical science, introduced into scientific circulation for the first time.

**Keywords:** Meryem Atmaja, Maryam Nigmatullina, dynasty of Tatar enlighteners Bubi, Bukhara People's Soviet Republic, Turkesrtan, Tatar emigration, Ali Ryza, Enver Pasha, Molla Nafiz, Zaki Walidi Togan.

**For citation:** Khairutdinov A.G. Mär'yam khanym: Bubilar näseleneŋ onytylgan kaharmany [Maryam Bubi: the forgotten hero of the Bubi dynasty]. *Istoricheskaya etnologiya*, 2022, vol. 7, no. 1, pp. 77–99. https://doi.org/10.22378/he.2022-7-1.77-99 (In Tatar)

## REFERENCES

Abdullaev K. *Ot Sin'tszyana do Khorasana. Iz istorii sredneaziatskoy emigratsii XX veka* [From Xinjiang to Khorasan. From the History of Central Asian Emigration of the Twentieth Century]. Dushanbe, Irfon Publ., 2009. (In Russian)

Guseva Yu.N. *Turetskie voennoplennye Pervoy mirovoy voyny v Samarskoy gubernii* [Turkish Prisoners of War of the First World War in Samara Province]. *Novyy istoricheskiy vestnik.* 2016, no 2 (48), pp. 97–112. (In Russian)

Makhmutova A.Kh. *Lish' tebe, narod, sluzhen'e! (Istoriya tatarskogo prosvetitel'stva v sud'bakh dinastii Nigmatullinykh-Bubi)* [Only to You, People, Service! (The History of Tatar Enlightenment in the Destinies of the Nigmatullins-Bubi Dynasty)]. Kazan, Magarif Publ., 2003. (In Russian)

Makhmutova A. *Gabdulla Bubi (1871–1922)* [Gabdulla Bubi (1871–1922)]. *Tatarskiye intellektualy: istoricheskiye portrery* [Tatar Intellectuals: Historical Portraits]. Compil. R. Muhametshin. 2th edit., Kazan, Magarif Publ., 2005, pp.172–188. (In Russian)

Sibgatullina A.T. *Kontakty tyurok-musul'man Rossiyskoy i Osmanskoy imperiy na rubezhe XIX-XX vv.* [Contacts of Muslim Turks of the Russian and Ottoman Empires at the Turn of the 19th–20th Centuries]. Moscow, Institut vostokovedeniya RAN Publ., 2010. (In Russian)

Yafarova Z.G. *Reforma turetskogo yazyka i ee otrazhenie na stranitsakh zhurnala «Khayat» (1926–1929)* [The Reform of the Turkish Language and its Reflection on the Pages of the Magazine "Hayat" (1926–1929)]. *Vestnik SPb GU.* 2015, ser. 13, issue 3, pp. 61–67. (In Russian)

**About the author:** Aidar G. Khairutdinov, Cand. Sc. (Philosophy), Senior Research Fellow of the Department of History of Religions and Social Thought, Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7A Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); khaidar67@mail.ru

*Received March 18, 2022* *Accepted for publication April 22, 2022*

УДК 93/94+929

# XX ГАСЫР БАШЫНДА ТАТАР АВЫЛЛАРЫНДА ХАТЫН-КЫЗ МӘГАРИФЕ ҮСЕШЕНЕҢ КАЙБЕР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Л.Р. Мортазина***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*lyalyamur@mail.ru*

***А.Ә. Зиннәтуллина***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*jamash.00@mail.ru*

Тәкъдим ителгән мәкаләдә XX гасыр башында татар хатын-кыз мәгарифенең авыл шартларында үсеш үзенчәлекләре карала. Шәһәрләрдә башлангыч алган җәдиди кызлар мәктәпләре татар авылларына да тиз арада үтеп керә. Төп үзенчәлекләрнең берсе булып элеккеге укыту системасына өстенлек бирүчеләр һәм яңача укытуга теләктәшлек белдерүчеләр арасындагы каршылыкның кискен булуы, аның кызлар мәктәпләре һәм мөгаллимәләр эшчәнлегенә йогынты ясавы тора. Нәтиҗәдә кайбер ачылган мәктәпләр ябыла, яңаларына юл чикләнә, мөгаллимәләр мәктәпләрне ташлап китергә мәҗбүр булалар. Бер үк вакытта алдынгы карашлы зыялылар, хатын-кыз мәгарифенең милли яшәешкә, аның киләчәгенә ни дәрәҗәдә уңай тәэсир итәчәген аңлаган мәгърифәтчеләр, тәртипкә салынган ирләр мәктәпләре булган авылларда, киресенчә, кызлар мәктәпләре уңышлы эшләп китә, гомумроссия күләмендә билгеле уку йортларына әвереләләр. Авторлар Иж-Бубый, Каргалы, Кышлау, Курса, Субаш-Аты һ.б. авыллардагы алдынгы кызлар мәктәпләре мисалында XX гасыр башында хатын-кыз мәгарифенең уңышлы якларын, үзенчәлекләрен һәм кайбер проблемаларны ачарга тырышалар. Мәкаләдә тарихта яхшы билгеле булган һәм моңарчы аз билгеле булган мөгаллимәләрнең эшчәнлеге һәм эш алымнары яктыртыла. Хезмәт XX гасыр башы татар вакытлы матбугаты материалларына нигезләнеп эшләнде.

**Ачкыч сүзләр:** җәдитчелек, хатын-кыз мәгарифе, кыз балаларга белем һәм тәрбия бирү, авыл, мөгаллимә.

XX гасыр башы – татар хатын-кыз мәгарифенең үсеш кичергән чоры. Бу – тарих мәйданына җәдитчелек хәрәкәте килү, шуның белән бәйле рәвештә мәгарифтә дә зур үзгәрешләр, яңалыклар күзәтелгән, аваз ысулына һәм дөньяви фәннәр укытуга корылган җәдиди мәктәпләр ачылган дәвер. Шәһәр мәдәни яссылыгында формалашкан яңа мәктәпләрнең авыл шартларына яраклашу, күпләп үтеп керүе дә нәкъ менә шушы чор белән бәйле.

Җәдитчелек хәрәкәтенең иң зур казанышларыннан берсе итеп хатын-кыз мәгарифен юлга салуны карарга кирәктер, мөгаен. Бу юлда бөек эшләр башкарган И. Гаспралы, хатын-кыз мәгарифенең әһәмиятенә басым ясап, «Бер милләтнең тәрәккые хатыннарның мәгариф юлына кертелүеннән башка мөмкин түгел», дигән фикерне әйткән (Ф.К. 1912). Бу фикер башка мәгърифәтчеләр – Ф. Кәрими, Р. Фәхретдин һ.б. хезмәтләрендә тагын да үстерелә.

Милләтнең алгарышы тәрбияле аналар җитештерүдән бәйле икәнлеге ачык билгеләнсә дә, ир балаларны укытуга игътибар күбрәк булып, баштагы чорда кызлар мәктәпләренә карата мөнәсәбәт берьяклырак була. XIX гасыр ахырларында – XX гасыр башында исә җәмгыятьтәге караш шактый үзгәреш кичерә, бай хатыннары үзләре мәктәпләр ачып, матди яктан кайгыртып, кыз балаларны укыта башлыйлар. Башлап шәһәрләрдә үсеш алган бу күренеш авылларга да үтеп керә. Каргалыда Гәүһәр Рәмиева, Уфа губернасы Килем авылында Суфия Җантуриналар мәктәп ача, Сембер губернасындагы Зөябаш авылында Маһруй, Мәргубә, Бәдриҗамал ханым Акчуриналар тарафыннан кыз балалар өчен ике шундый мәктәп оештырыла, әлеге затларның тырышлыгы белән дәрәҗәле уку йортларына әверелә (XX гасыр башы 2020: 123–124).

Әлбәттә, җәдиди мәктәпләрнең барлыкка килүе иң беренче чиратта алдынгы карашлы шәхесләр, мәгърифәтче-педагоглар эшчәнлеге белән бәйле. Яңача укытуга нигезләнгән кызлар мәктәпләрен дә башлап җәдит муллаларының абыстайлары ачуы шөбһәсез. Мисал өчен, Казан шәһәрендә атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең җитәкчесе Галимҗан Барудиның җәмәгате Маһруй ханым 1890 елда шундый мәктәпкә нигез сала. Билгеле булганча, бу төр мәктәпләрне татар авылларында да алдынгы карашлы муллалар һәм аларның гаилә әгъзалары ача. Казан губернасы һәм өязе Кышлау (Койтамас) авылының мулласы Лотфулла ахунд, мәсәлән, үз авылында кыз балаларны укытыр өчен мәктәп оештыра, биредә аның кызлары – бертуган Галимәтелбәнат, Гайшә, Гафифә, Фатыйма белем ала. Киләчәктә алар үзләре дә, этиләре юлын дәвам итеп, мәгърифәтчелек юлына басалар, мәктәпләр ачалар (Фәхреддин 2010: 335, 438). Лотфулла ахунд мәктәбе заманы өчен шактый югары дәрәҗәле уку йорты саналган, программалар, планнар нигезендә эш алып барылган бу хосусый мәктәп мөгаллимәләр әзерләүче дарелмөгаллимат ролен үтәгән (Мәхмүтова 2012: 24). Галимнәрнең билгеләп үтүенчә, бу – авыл

шартларында барлыкка килгән беренче җәдит кызлар мәктәбе дә булып тора (Биктимирова 2002: 31).

Лотфулла ахундның кызларыннан берсе, мәгърифәтче һәм кыз балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышланган китаплар авторы Галимәтелбәнат Биктимерия, кияүгә чыкканнан соң, Рязань губернасы Яубаш авылында яңа тәртипкә корылган кызлар мәктәбе ачып җибәрә, аны заманының иң алдынгы мәктәпләре рәтенә күтәрүгә ирешә. Киләчәктә ул Яубаш авылында мөгаллимәләр әзерләү өчен ике еллык кызлар мәктәбе ачу, мәктәпнең уку программасына география, табигать, тарих кебек дөньяви фәннәрне кертү турында хыяллана (Гайнуллин 1988: 42).

Гомумән алганда, XX гасыр башында татар хатын-кыз мәгарифе үсешендәге иң зур үзенчәлекләрнең берсе булып аның авыл шартларында үсеш алуы тора. Авыл мәктәпләре арасында татар дөньясында зур шөһрәт казанган уку йортлары барлыкка килә. Дөньяви фәннәрне, рус телен укытуга, чигү-тегү эшләренә зур әһәмият бирелгән «Буби» кызлар мәдрәсәсе шундыйларның берсе булган. Аның даны еракларга таралган. Хәтта Мәскәү, Себер кебек ерак җирләрдән кыз балалар Бубига килеп укырга тырышканнар. 1903 елда Мәскәү сәүдәгәре Хаҗи Дунаевның кызы Хәдичә[1], Мәскәүдә «кызларга махсус тәртипле бер ысул җәдидә мәктәбе түгел, мәктәп исемен алырлык бер ысул кадим мәктәбе дә булмау» сәбәпле, Мәскәүдән шактый гына ерак булган, «дахили Русия мөселманнары арасында тәртипле вә низамлы уку-укытуы илә таныла башлаган, тәртипле Буби мәдрәсәсенә» укырга килә (Дунаева 1916). Шәһәр һәм авыл мәктәпләрендә укытучы татар мөгаллимәләре, сәләтлерәк кыз балаларны аерым хәзерләп, мөгаллимә булыр өчен Буби мәдрәсәсенә җибәрә торган булганнар. Чистай, Кәрәкәшледә укыткан Фатыйма-Фәридә Нәүрузованың укучылары белем алуларын Буби мәктәбендә дәвам иткәннәр.

Бубида белем алган мөгаллимәләр үзләре дә төрле төбәкләрдә мәктәпләр ачып, кыз балаларга белем һәм тәрбия биргәннәр. Алда искә алынган Х. Дунаева 1906 елда үз йортларында кыз балаларны укыта башлый. Бу вакытта Мәскәүдәге әлеге мәхәлләдә җәдит ысулы белән укыта торган тәртипле ир балалар мәктәбе дә булмый әле (Мәскәүдә 1906). Шул ук вакытта XX гасыр башында татарлар яшәгән күп кенә авылларда шактый алга киткән җәдиди мәктәпләр инде булган. Мәсәлән, 1908 елда Уфа өязенең Шәрип авылында махсус бина тәгаенләнеп, кызлар өчен мәктәп ачыла. Авыл имамының җәмәгате Мәрьям ханым һәр көн иртәнге 8 дән көндезге 2 гә кадәр кыз балаларга белем бирә. Уфадан Хәсән Кәримов дәреслекләр белән тәэмин итә. Әйбәт кенә эшләп киткән мәктәп авыл халкы өчен күп шатлыклар китерсә дә, кайбер иске карашлы кешеләрнең коткысына бирелеп, ата-аналар арасында «балаларыбызны

[1] «Вакыт» газетасының хәбәр итүенчә, 1906 елда Хәдичә Дунаева ахунд Агиев тарафыннан рөхсәт алып, үз йортларында кыз балаларны укыта башлый (Мәскәүдә 1906).

партага утыртып, кара тактага яздыртып укытмасыннар, безнең кызларыбыз язу белеп писер булачак, вә хисап белеп конторщик булачак түгел, "Һәфтияк" иҗеге укылса, җитәр», диючеләр күренә (Уфа өязе 1908).

Чынлап та, яңа төр мәктәпләргә һәм алардагы укыту тәртипләренә генә түгел, яңа ысул белән белем бирергә ашкынып йөргән яшь мөгаллимәләргә карата да халыкның мөнәсәбәте төрлечә була. Шәһәр халкы бу мәсьәләгә күбесенчә уңай караштa булса, кайсыбер авылларда халык, күпчелек очракта, иске карашлы дин әһелләренең фикерләренә ияреп, каршы чыга. XX гасыр башы вакытлы матбугаты битләрендә авыл халкының мулла-абыстай сүзләрен өстен күрүләрен ачык тасвирлаган, яшь мөгаллимәләрнең аянычлы язмышларын сурәтләгән мәкаләләр еш очрый. Мәсәлән, Хәлимә исемле бер яшь мөгаллимәнең абыйсы, кызның үзенә язган хатларына нигезләнеп, аның авылга эшкә килгәч күргән хәлләрен сурәтләп «Сөембикә» журналына мәкалә җибәрә: «Килгән көннәр яхшы үтте: авыл кызлары аны яраттылар, авыл хатыннары да аны үзләренең гайбәтләрен иренмичә тыңлавы өчен сөйделәр. Ул аларны ни эшләргә белмичә тыңлады. Мәҗлесләр күңелле үтте, мәктәпне ачу да матур булды. Икенче атнада аңа уңайсыз тормыш башланды. Карт остазбикә иҗек урынына әллә нинди "арба-чаналар" укытуы өчен, аңар теге дөньяда җәһәннәмнең иң кызуында урын вәгъдә итте, шуны бөтен авылга таратты. Яшь бай[2] хатыны, бай бер мәртәбә мәктәпкә кергәч тә Хәлимәгә көнләде, әллә нинди карчыклар аша Хәлимәне куркыта башлады. Аңа каршы сугыш ачты. Авыл хатыннары бөти язып бирмәгәне өчен аны эт итеп сүгә башладылар» (Фәхри 1914: 9–11). Нәтиҗәдә яшь мөгаллимә үзенең яраткан шөгылен ташлап, бу авылдан китәргә мәҗбүр була.

Шулай итеп, аеруча авыл шартларында, җәмгыять ике төркемгә бүленә. Бу бүленеш хатын-кыз мәгарифенә карата кешелек җәмгыятендә булган гомуми караш белән тәңгәл килә. Берәүләр: «Хатыннар бала тәрбиясе вә йорт карау өчен яратылганнар. Аларның яратылмышлары ошбуның өчен генә улдыгы җәһәтле, аларга гаилә мәгыйшәте вә бала тәрбиясе генә укытырга кирәк. Гали фәннәр илә башларын ватарга тиеш түгел, дисәләр, бәгъзеләре исә фәннәр тәрбиясенә башка күзлектән карап, аларны да ирләр илә бер дәрәҗәдә укытуның ляземен сөйли иделәр» (Хатын-кыз 1908: 614). Кыз балаларга белем бирүгә каршы төшүчеләр, әлбәттә, җәмгыятьтәге бу «шайтан укытуының» (Ибраһимов 1908), мәһшәрнең төп «сәбәпчесе» итеп мөгаллимәне күрәләр һәм аңа һәртөрле каршылыклар тудыралар. Бу каршылык мөгаллимәләрне кабул итмәү, куып җибәрүдә генә түгел, эшкә керешкәннәренә ярдәм итмәүдә дә ачык чагылыш таба. Яшь, әле тормышта булмаган, ялгыз мөгаллимәләргә аеруча матди якны, тормыш-көнкүреш шартларын җайлау авыр була. Берәүләр булган шартларга риза булып, ачлы-туклы яшәргә тырышкан, икенче берәүләре, авырлыкларга түзә алмый, авылны калдырып китәргә

---

[2] Әлеге мәктәпне ачкан бай турында сүз бара.

мәҗбүр булган. Бөгелмә өязендәге бер авылга зур мәшәкатьләр белән барып урнашкан мөгаллимә Зәкия туташ Шакирия 10 сум акча түләп фатир алуы, аны җылыту, яктырту мәсьәләсен хәл итүнең үзенә калуы, 25 кыз баланы туплап укыта башлавы, һәрберсеннән берәр сүм күләмендә уку хакын билгеләсә дә, ел дәвамында бу акчаның яртысы да җыелмавыннан зарланып, «Тормыш» газетасына язмасын юллый. «Хәзер нишләргә инде? Чигеш, бәйләү эшен белсәм дә, матдәсен алырга акчам юк», – дип яза ул, гаҗизлектән нишләргә белмичә (Аянычлы 1915). Моннан тыш, мөгаллимәләргә эшкә урнашу да бик үк җайлы булмаган. Алда искә алынган Зәкия туташ, курсларда укып, шәһадәтнамә алса да, берничә җиргә мөрәҗәгать итеп тә, тиз генә эш урыны таба алмый (Аянычлы 1915). Шул ук вакытта татар газеталарында теге яки бу авылга мөгаллимә чакырып, аңа карата куелган таләпләрне билгеләп (шәһадәтнамә булуы, белем дәрәҗәсе югары булу, күркәм холкы һ.б.) басылган игъланнар да еш очрый. Димәк, карашларның төрлелегенә карамастан, XX гасыр башында җәмгыятьтә кыз балалар мәктәпләренә һәм мөгаллимәләргә булган ихтыяҗ зур була.

Авыл мәктәпләрендә, шәһәрләрдәге кебек үк, иң зур игътибар кызларны кул эшләренә өйрәтүгә бирелгән. Чөнки көндәлек тормышта кирәкле күнекмәләрне, бигрәк тә кул һөнәрләрен белү хатын-кызның гаиләдәге хәлен җиңеләйткән, матди яктан да файдалы булган. Бөре өязе Борай авылындагы кызлар мәктәбендә, мәсәлән, 1913 елда барлыгы 23 төрдәге кул эшләренә өйрәткәннәр (Бөре өязе 1913). Бәдриҗамал Акчуринаның кызлар мәктәбендә моның өчен хәтта махсус зал да ясалган була (XX гасыр башы 2020: 129). Богырыслан өязе Иске Колумбәт авылындагы башлангыч мәктәптә оек, ашъяулык, эскәтер, челтәр бәйләргә, кисү, машина белән тегү кебек эшләргә өйрәткәннәр. Мәктәпнең назыйре мулла Ибраһимов кызларның кул эшләренә өйрәнүләренә аерым әһәмият биргән (Кызларга 1912). Татар җәмгыяте кыз балаларга һөнәр өйрәтүгә уңай караган, чөнки заманча таләпләргә туры китереп, «Яурупа модасы илә күлмәк тегә» (Фатыйма-Фәридә 1912) алырлык осталарны тәрбияләү милләт мәнфәгатьләрен кайгыртуның бер юлы булып саналган, капиталны башка милләт кулына җибәрүдән саклаган.

Һөнәргә өйрәтү бер үк вакытта кыз балаларны мәктәпләргә тартуның бик уңышлы формасы да булган. Күпчелек ата-аналар, кызларын мәктәпләргә биргәндә, иң беренче чиратта аларның кул һөнәрләренә өйрәнүләренә басым ясаганнар. Алар кызлар мәктәпләрендә өйрәтелә торган челтәр бәйләү, сөлге башларын чигү белән мавыкмаска («фәкыйрь ата кесәсенә сизелерлек кыйбат төшә», «бөтен гаилә өчен матди файдалары юктыр»), ә көн дә кирәк булган оек бәйләү, тегү кебек һөнәрләргә өйрәтергә киңәш итәләр (Кызлар өчен 1911). «Вакыт» газетасы хәбәр

итүенчә, Әстерхан вилаяте Новая Казанка авылында[3] 1911 елда бертуган Сәгыйдевләр тарафыннан нигез салынган кызлар мәктәбенең «төп максаты да кызларымызны кул эшләре белән таныштырып, идарәи бәйтия [хуҗалык эшләре], тәрбияи әүляд [балалар тәрбияләү] кеби кирәкле мәгълүматлар илә белештерү» була (Латыйф 1915).

Авыл балаларына, кызларга тормышта кирәк булган һөнәрләрне өйрәтү мәҗбүрилегенә мәктәпне оештыручылар үзләре дә игътибар иткәннәр. Бу уңайдан мөфти Сәлимгәрәй Тәфкилевның агасы Сәетгәрәй Тәфкилев кызы, танылган сәясәтче һәм эре алпавыт Сәлимгәрәй Җантуринның тормыш иптәше Суфия Җантурина шәхесенә һәм аның эшчәнлегенә аерым тукталып китү дөрес булыр.

Суфия ханымга Килем авылында (хәзерге Башкортстанның Бүздәк районындагы татар авылы) зур гына бер утар мирас булып калган. Әлеге авылда Суфия ханым авыл балаларына тормыш итәргә яраклы һөнәр өйрәтү максаты белән тукуханә ачып җибәрергә ниятли. Башта үзе, Петербургка барып, туку һөнәрен үзләштерә, соңыннан остаханәне кирәкле барлык җиһазлар белән тәэмин итеп, балаларны да өйрәтә башлый (Ш.Ә. 1916: 377–381). Остаханә булдырганчы, Суфия ханым авылда эшләп килгән иске ысуллы мәдрәсәгә дә үзгәрешләр кертә, кыз балалар өчен мәктәп ачып җибәрә. Ир һәм кыз балалар мәктәпләре өчен аерым биналар салып, укымышлы мөгаллимнәр китертә. 1915 елда инде Килем авылы мәктәпләрендә барлыгы 282 бала белем алган дигән мәгълүмат бар (Мөхәммәтфазыл 1915).

Уку-укыту эшенең оештырылышы ягыннан караганда, күп кенә авыл мәктәпләре шәһәр мәктәпләреннән калышмаганнар. Курса авылындагы аерым программа нигезендә эшләгән 8 еллык кызлар мәктәбендә, мәсәлән, тарих, хисап, география, татар, гарәп телләре бик яхшы дәрәҗәдә укытылган, моннан тыш, кыз балаларны көндәлек тормыштагы хуҗалык хезмәтенә, кул эшләренә өйрәтүгә зур әһәмият бирелгән. Биредә чит авыллардан килеп укучылар өчен пансион да булган хәтта. Мәктәптә, заманча белем һәм тәрбия бирүдән тыш, укучыларның сөйләм телен, фикерләү сәләтләрен үстерүгә басым ясалган. Һәр җомга көнендә укучы кызлар һәрберсе аерым бер тема алып, шул тема буенча иптәшләре алдында чыгыш ясаган. Мәктәпне тәмамлаучылар тирә-юнь авылларда мөгаллимәлек эшен дәвам иткәннәр. Курса мәктәбе заманының алдынгы уку йортлары арасында саналган, аның тәҗрибәсен татар мәктәпләрендә генә түгел, хәтта башка мөселман, әйтик, Кавказ, Төркестан халыклары өчен дә үрнәк итеп алу мөмкинлеге каралган (Аягузи 1916: 51–56).

---

[3] Җаңаказан авылы бүгенге көндә Казахстанның көнбатыш өлкәсендә урнашкан.

Курсадан ерак булмаган Субаш-Аты авылының кызлар мәктәбендә дә укучыларның фикерләү сәләтләрен үстерүгә зур игътибар бирелгән. Казанда Ф. Аитова мәктәбендә белем алган мөгаллимә Марзия туташ дәрестән тыш вакытта кызларны әдәби китаплар укуга тарта, фикерләрен сорый, аларны әдипләрнең тәрҗемәи хәлләре белән таныштыра, моңа кадәр күзәтелмәгән, гадәти саналмаган музыка, җыр дәресләрен укыта (Аягузи 1917: 78).

Бу чорда хатын-кыз мәктәпләре өчен махсус язылган дәреслекләр, уку китаплары барлыкка килә. Мәгърифәтче ханымнар үзләренең кыз балаларга белем һәм тәрбия бирүдәге тәҗрибәләренә таянып, аларга нинди рухтагы китаплар, ә мөгаллимәләргә нинди методик ярдәм кирәклеген күзаллап, әсбаплар төзеп бастыралар. Бу авторлар арасында шәһәр мәктәпләре педагоглары белән беррәттән, авыллардагы кызлар мәктәпләрендә эшләгән мөгаллимәләр дә була. Г. Биктимерия, мәсәлән, Яубаш авылында укыткан дәверендә берничә шундый китап әзерләп бастыра. Димәк, мәгариф өчен бик әһәмиятле булган дәреслекләр проблемасын хәл итүдә авыл мөгаллимәләре дә катнашкан. Бу исә аларның методик яктан әзерлекләре, иҗади тәҗрибәләре бай булу турында сөйли[4].

Шулай итеп, XX гасыр башында татар авылларында хатын-кыз мәгарифе үсеш дәрәҗәсе буенча шәһәрләрдән сизелерлек дәрәҗәдә аерылмаган. Әлбәттә шәһәр шартларында уку-укыту әсбаплары, укытучы кадрлар белән тәэмин ителеш мәсьәләләрен хәл итү беркадәр җиңелрәк булган. Шәһәрдә башлангыч алган хатын-кыз мәгарифе авылларга да тиз арада үтеп керә, зур тизлек белән үсеп китә, һәм хәтта кайбер аерым мәктәпләр тирә-юньдә генә түгел, Россиянең татар-мөселман халкы арасында да шактый киң билгеле булып, зур абруйга ирешә. Бу уңышның нигезендә иң беренче чиратта әлеге мәктәпләрне оештыручыларның, аны матди яктан тәэмин итүчеләрнең һәм, әлбәттә, педагогларның роле зур була.

## ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ МАТЕРИАЛЛАР

XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында хатын-кыз мәсьәләләре / төз.-авт. Мортазина Л.Р., Зиннәтуллина А.Ә. Казан: ТР ФА Ш.Мәрҗани ис. Тарих ин-ты, 2020.

Аягузи С. Авылларда кызлар мәктәбе // Сөембикә. 1916. № 3–4.

Аягузи С. Авылларда мәктәпләре // Сөембикә. 1917. № 5.

Аянычлы мөгаллимәләребез // Тормыш. 1915. 18 март.

Бөре өязе Борай карьясендә // Вакыт. 1913. 17 май.

[4] Бу турыда тулырак «Татар тәрбиясе: Г. Биктимерия һәм Ф. Сөләймания хезмәтләрендә гаилә тәрбиясе мәсьәләләре» китабында карарга мөмкин (Татар тәрбиясе 2021).

Дунаева Х. Мөхтәрәмә Фатыйма-Фәридә ханым хакында сабыйлык хатирәләрем // Сөембикә. 1916. № 9.

Ибраһимов Гали. Ачык хат // Вакыт. 1908. 10 гыйнвар.

Кызларга кул һөнәрләре өйрәтү // Вакыт. 1912. 3 гыйнвар.

Кызлар өчен кул һөнәрләре // Вакыт. 1911. 29 март.

Латыйф Х. Мөселман авылында һөнәр өйрәтү // Вакыт. 1915. 17 апрель.

Мәскәүдә // Вакыт. 1906. 3 октябрь.

Мөхәммәтфазыл Х. Җантуриннар мәдрәсәсендә // Тормыш. 1915. 1 гыйнвар.

Татар тәрбиясе: Г.Биктимерия һәм Ф.Сөләймания хезмәтләрендә гаилә тәрбиясе мәсьәләләре / төзүче-авторлар Мортазина Л.Р., Зиннәтуллина А.Ә. Казан: ТР ФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих институты, 2021.

Уфа өязе // Вакыт. 1908. 15 гыйнвар.

Фатыйма-Фәридә. Хатын-кызга бер дә права бирмәенчә... // Сибирия. 1912. 19 август.

Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. Казан: Рухият, 2010.

Фәхри А. Авылда мөгаллимә (сеңелем сөйләде) // Сөембикә. 1914. № 22.

Ф.К. Һиндстанда беренче ысул саутия мәктәбе // Вакыт. 1912. 29 март.

Хатын-кыз мәктәпләре // Шура. 1908. № 19.

Ш.Ә. Мәшһүр хатыннардан Суфиябикә һәм анасы // Сөембикә. 1916. № 23.

## ФӘННИ ӘДӘБИЯТ

Биктимирова Т.Ә. Татар хатын-кызлары мәгърифәт юлында. Казан: Печатный Двор, 2002.

Гайнуллин М. Өмет йолдызлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.

Мәхмүтова А.Х. Вакыт инде: без дә торыйк… (Җәдидчелек һәм хатын-кызлар хәрәкәте формалашу): очерклар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012.

**Авторлар турында белешмә:** Мортазина Ләлә Рәис кызы – педагогика фәннәре кандидаты, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге, Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты (420111, Батурин ур., 7А, Казан, Россия Федерациясе); lyalyamur@mail.ru

Зиннәтуллина Алсу Әнвәр кызы – фәнни хезмәткәр, Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге, Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты (420111, Батурин ур., 7А, Казан, Россия Федерациясе); jamash.00@mail.ru

*Редакциягә керде 08.02.2022* *Кабул ителде 22.03.2022*

# НЕКОТОРЫЕ ОСОБЕННОСТИ РАЗВИТИЯ ЖЕНСКОГО ОБРАЗОВАНИЯ В ТАТАРСКИХ ДЕРЕВНЯХ В НАЧАЛЕ XX ВЕКА

***Л.Р. Муртазина***

*Институт истории им. Ш. Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*lyalyamur@mail.ru*

***А.А. Зиннатуллина***

*Институт истории им. Ш. Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*jamash.00@mail.ru*

Статья посвящена анализу некоторых проблем и особенностей развития женского образования среди татар вне города. Женские школы, впервые появившиеся в городах, начали открываться и в татарских деревнях. На развитии и становлении этих школ негативно отразились противоречия между сторонниками старометодного и новометодного обучения. Очень часто народ оказывался на стороне первых, в результате чего женские школы вынуждены были закрываться, а преподавательницы отстранялись от своих обязанностей. В тех деревнях, где преобладало новое мышление, благодаря деятельности прогрессивных просветителей школы развивались и становились известными в общероссийском масштабе. Авторы попытались на примере женских школ в деревнях Иж-Бобья, Кышлау, Курса, Субаш-Аты и др. определить приоритеты и особенности развития женского образования в условиях деревни. В статье использованы публикации татарской периодической печати начала XX века.

**Ключевые слова:** джадидизм, женское образование, обучение и воспитание девочек, деревня, *мугаллима*.

**Для цитирования:** Муртазина Л.Р., Зиннатуллина А.А. XX гасыр башында татар авылларында хатын-кыз мәгарифе үсешенең кайбер үзенчәлекләре // Историческая этнология. 2022.Т. 7, № 1. С. 100–110. https://doi.org/10.22378/he.2022-7-1.100-110

**Сведения об авторах:** Муртазина Ляля Раисовна – кандидат педагогических наук, ведущий научный сотрудник Центра истории и теории национального образования Института истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан (420111, ул. Батурина, 7А, Казань, Российская Федерация); lyalyamur@mail.ru

Зиннатуллина Алсу Анваровна – научный сотрудник Центра истории и теории национального образования, Институт истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан (420111, ул. Батурина, 7А, Казань, Российская Федерация); jamash.00@mail.ru

*Поступила 08.02.2022* *Принята к публикации 22.03.2022*

## SOME FEATURES OF THE DEVELOPMENT OF WOMEN'S EDUCATION IN TATAR VILLAGES IN THE BEGINNING OF THE 20th CENTURY

***L.R. Murtazina***
*Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*lyalyamur@mail.ru*

***A.A. Zinnatullina***
*Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*jamash.00@mail.ru*

This article is devoted to the analysis of some problems and features of the development of women's education among the Tatars in the countryside. Women's schools first appeared in cities. Then they began to open in the Tatar villages. The development of these schools was reflected in the contradictions between the supporters of the old-method teaching and the Jadids. Very often the people were on the side of the former. As a result, women's schools were forced to close and teachers lost their jobs. In some villages, thanks to the activities of progressive people, schools developed and became famous in Russia. The authors give examples of such schools and teachers. The work uses the publications of the Tatar periodical press of the early 20th century.

**Keywords:** Jadidism, women's education, education and upbringing of girls, village, teacher.

**For citation:** Murtazina L.R., Zinnatullina A.A. XX gasyr bashynda tatar avyllarynda khatyn-kyz mägarife üsesheneñ kayber üzenchälekläre [Some features of the development of women's education in Tatar villages in the beginning of the 20th century]. *Istoricheskaya etnologiya*, 2022, vol. 7, no. 1, pp. 100–110. https://doi.org/10.22378/he.2022-7-1.100-110 (In Tatar)

### REFERENCES

Biktimirova T.A. *Tatar hatyn-kyzlary megrifet yulynda* [Tatar women on the path of enlightenment]. Kazan: Pechatnyj Dvor Publ., 2002. (In Tatar)

Gajnullin M.Omet joldyzlary. Kazan, Tatar. Book Publ., 1988. (In Tatar)

Makhmutova A.Kh. Vakyt inde: bez de toryjk… : ocherklar [The Time Has Come: Let Us Rise: Essays]. Kazan, Tatar. Book Publ., 2012. (In Tatar)

**About the authors:** Lyalya R. Murtazina, Cand. Sc. (Pedagogy), Leading Research Fellow of the Center of History and Theory of National Education, Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7A Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); lyalyamur@mail.ru

Alsou A. Zinnatullina, Research Fellow of the Center of History and Theory of National Education, Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7A Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); jamash.00@mail.ru

*Received February 8, 2022* *Accepted for publication March 22, 2022*

УДК 297.1

# Г. БУБИНЫҢ «ЗАМАНЕ ИҖТИҺАД МӨНКАРЫЙЗМЫ, ДӘГЕЛМЕ?» КИТАБЫ ХАКЫНДА

***А.М. Гайнетдинов***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*aydargm@yandex.ru*

Күренекле татар галиме, мәгърифәтче, педагог, җәмәгать эшлеклесе Габдулла Бубиның (1871–1922) педагогика, логика, ислам дине буенча кыйммәтле хезмәтләре бар. Әлеге мәкаләдә Габдулла Бубиның татар телендә басылып чыккан хезмәтләреннән берсе – 1909 елда «Милләт» типографиясендә дөнья күргән *«Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?»* китабы карала. Автор Буби әсәрен югары бәяли, аңарда чагылдырылган мәсьәләләрне билгели, бу эшнең гарәп галиме Ибн Кайййимнең *«А'лам ал-муваккиин 'ан рабб ал-'аламин»* хезмәтенең тәрҗемәсе генә түгел, ә өчтән берен Буби үзе язган икәнен раслый. Мәкаләдә шулай ук кайбер цитаталарның тарихчылар тарафыннан рус теленә бик үк төгәл тәрҗемә ителмәгән очраклары да күрсәтелә.

**Ачкыч сүзләр:** Габдулла Буби, «Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?», ислам, татар илаһият гыйлеме, иҗтиһад, тәклид, мәзһәб.

Габдулла Буби (Габдулла бине Габделгалләм бине Нигъмәтулла бине Монасыйп) – мәшһүр дин галиме, мәгърифәтче, педагог, публицист, җәмәгать эшлеклесе. Мәгълүм булганча, ул 1871 елның 9 (21) ноябрендә хәзерге Татарстан Республикасы Әгерҗе районы Иж-Бубый авылында мулла гаиләсендә дөньяга килгән. Төпле белемне атасының мәдрәсәсендә алганнан соң, 1895 елда Г. Буби Иж-Бубый авылына имам һәм мөдәррис итеп билгеләнгән. Мәдрәсәдәге укыту һәм тәрбия процессы тулысынча аның кулына күчкәч, Г. Буби төпле дини һәм дөньяви белем бирүче абруйлы мәгърифәт учагы булдырган. 1905–1906 елларда ул, Мәккә, Мәдинә, Каһирә, Бәйрут, Истанбул һ.б. шәһәрләргә сәяхәт кылып, белемнәрен камилләштергән. Кызганычка каршы, кадимчеләрнең яла ягулары аркасында, 1911 елда данлыклы Иж-Буби мәдрәсәсе ябылган, шәкертләре куып таратылган. Шуннан соң 1913 елда Г. Буби гаиләсе белән Кытайның Голҗа шәһәренә күченеп киткән, анда татар мәдрәсәсе оештырган.

Февраль инкыйлабыннан соң Русиягә кайткач, ул Троицк шәһәрендә кызлар мәдрәсәсендә укыткан, соңыннан 1918 елның җәендә исә туган авылындагы мәктәпне торгызган. Галим 1922 елның 7 февралендә туган авылы Иж-Бубыйда вафат булган. Шундагы зиратта җирләнеп, газиз анасы Бәдрелбанат белән Габдулла Бубиның икесенә бер кабер ташы куелган. Тексты түбәндәгечә:

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Лилләәһил-фәәтихәһ
2) Бәдрелбанат
3) Иманкол кызы
4) Буби
5) вафат 1923 нче
6) йылда 85 йәшендә
7) Аллаһ рәхмәт кыйлсун».

Арткы ягы (уеп язылган):

1) «Бу тарафта
2) Габдулла
3) Габделгалләм углы
4) Буби
5) вафат 1922 сәнә
6) 51 йәшендә
7) гафәраллааһү зүнүүбәһ» (Кайбер төзәтмәләр белән: Мәрданов, Һадиев 2003: 47).

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе:

Алгы ягы: «Аллаһ ризалыгы өчен “Фатиха” сүрәсен укы. Бәдрелбанат Иманкол кызы Буби 1923 елда 85 яшендә вафат. Аллаһ рәхим кылсын».

Арткы ягы: «Бу тарафта Габдулла Габделгалләм улы Буби 1922 елның 7 февралендә 51 яшендә вафат. Аллаһ аның гөнаһларын кичерсен».

Г. Буби байтак кыйммәтле хезмәтләр язып калдырган: *«Мөкяләмәи гарәбия»* («Гарәп телендә сөйләшү»), *«Фәраиз»* («Фарыз гамәлләр»), *«Логия яхуд Мантыйк фәне»* («Логика, яки Мантыйк фәне»), *«Тәгаддөде зәүҗати хифзы сыйххәти тәтъбикъ»* («Күпхатынлылыкны сәламәтлек саклауга килештерү»), *«Мохтасар нәхү гарәби»* («Кыскача гарәп теле синтаксисы»), *«Тәзәүвеҗдә сәгадәт»* («Никахлашуда бәхет»), *«Тәрәкъкые фөнун вә мәгариф динсезлеге мөҗибме?»* («Фәннәрнең һәм мәгарифнең алга китүе динсезлеккә сәбәпчеме?»), *«Хакыйкать яхуд Тугрылык»* («Хакыйкать, яки Дөреслек») (8 кисәктән тора), *«Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?»* («Иҗтиһад заманы үттеме, юкмы?»), *«Татарча хөтбә уку дөресме?», «Гыйльме хәл»* («Ислам гыйлеме»), *«Сарфы гарәби»* («Гарәп теле морфологиясе»), *«Бубый мәдрәсәсенең кыскача тарихы», «Зиндан», «Хатыннар»* һ.б. Ләкин аның *«Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?»* дигән китабы башкаларыннан аерылып тора, чөнки анда ул заманда гына түгел, хәтта хәзерге заманда да бик актуаль булган дини проблемалар күтәрелгән. Галимнең 1909 елда «Милләт» типографиясендә

басылып чыккан әлеге бибәһа хезмәте тулысынча иҗтиһад һәм тәкълид мәсьәләләренә багышланган.

Иҗтиһад – нинди дә булса дини мәсьәләдә, Коръән һәм хәдисләргә таянып, үзлегеңнән хөкем, нәтиҗә чыгару, ә тәкълид дин галимнәренең фикерләренә сукырларча иярүне аңлата. Ислам динендә дүрт хокукый юнәлеш яки дүрт мәзһәб барлыкка килеп, алар ныклап тамыр җәйгәннән соң, X–XI гасырларда ислам дөньясында, хәзер беркем дә үзлегеннән, турыдан-туры Коръән һәм хәдисләргә мөрәҗәгать итеп, теге яки бу дини сорауга җавап эзләргә тиеш түгел, барысы да мәзһәб галимнәре тарафыннан өйрәнелгән, шуңа күрә аларга ияру мәҗбүри, дигән караш хасил булган һәм шул рәвешле «иҗтиһад ишекләре» ябылган. Әмма байтак акыл ияләре, шул исәптән татар галимнәре, моның белән килешә алмаганнар, әлбәттә. Беренчеләрдән булып Г. Курсави XIX йөз башында ук дини фикердә инкыйлаб ясаган: бөтен татар-ислам дөньясын тәкълид бәласеннән коткарырга ниятләгән, кәлям әһелләре булган матүридиләрнең өйрәтмәләренә каршы чыккан, «иҗтиһад ишекләре»н ачарга чакырган, халыкның акылына салынган богауларны өзәргә омтылган. Г. Курсави юлын күренекле галим Ш. Мәрҗани дәвам иткән һәм аның идеяләрен тагын да үстергән, популярлаштырган. Шиһаб хәзрәт үзенең хезмәтләре белән бөтен ислам галәмен диярлек тетрәндергән, уйланырга мәҗбүр иткән. Ул да халыкны аң-белемгә, иҗтиһадка, схоластика һәм тәкълидтән арынырга, Коръән һәм хәдисләргә мөрәҗәгать итеп, акылы булган һәр кешене шәригать мәсьәләләрендә хөкем чыгарырга, элекке галимнәрнең ялгыш фикерләреннән арынырга, мөстәкыйль рәвештә фикер йөртергә өндәгән. Шулай ук Р. Фәхретдин, Г. Баруди, З. Камали, М. Бигиев кебек башка дин галимнәребез үзләренең хезмәтләрендә иҗтиһад һәм тәкълид проблемасын шул рухта яктыртканнар. Гомумән, җәдидчеләрнең күпчелеге мәзһәбләрне кире каккан (Хакимов 2015: 28).

Г. Буби да *«Замане иҗтиһад...»* хезмәтендә бу мәсьәләләрне энәсеннән җебенә кадәр җентекләп аңлаткан, үзенең сүзләрен куәтләү өчен бик күп дәлилләр китергән һәм бернинди шик-шөбһәләргә урын калдырмаган. Аны язганда, автор түбәндәге төп чыганакларны кулланган: Коръән, хәдисләр, мәшһүр гарәп галиме Ибне Кайийм әл-Җәүзиянең (1292–1350) *«Игълям әл-мөвәкъкыйгыйн»* («Галәмнәрнең Раббысы исеменнән имза куючыларга белдерү») китабы, гарәп дин һәм җәмәгать эшлеклесе Мөхәммәд Рашид Риданың (1865–1935) *«Реформатор белән мөкаллиднең бәхәсе»* хезмәте. Шулай ук Г. Буби Шатыйбиның *«Мувәфәкать»* («Муафыйклыклар»), Тафтазаниның *«Хашия-и Гадудия»* («Гадуди хашиясе»), Мәргыйнаниның *«Әл-Һидая»* («Туры юл»), Мәхбубиның *«Мохтасар әл-Викая»* («“Саклау” хезмәтенең кыскача аңлатмасы»), Хәләбинең *«Мөлтәка әл-әбхур»* («Диңгезләр кушылуы»), Шәехзадәнең *«Мәҗмәгъ әл-әнһәр»* («Елгалар җыелмасы»), Ибне Һөмамның *«Фәтх әл-Кадыйр»* («Кодрәтле Аллаһның [хакыйкатьне] ачуы») хезмәтләренә дә мөрәҗәгать иткән. Ни өчендер 1909 елгы басмада Ибне Кайийм

китабының исеме *«Игълям әл-мөвәффәкыйн»* дип бирелгән (Буби 1909: 23, 63), бу – типография хатасы булса кирәк.

Кайбер тарихчылар, *«Замане иҗтиһад...»* хезмәтен Г. Буби үзе язмаган, фәкать *«Игълям әл-мөвәкъкыйгыйн»* китабын гарәп теленнән татарчага тәрҗемә иткән, дип ялгышалар (Адыгамов 2015: 146). Бу сүзләре белән алар әлеге китап белән тулысынча танышып чыкмаганлыкларын, аны игътибар белән укымаганлыкларын күрсәтәләр. Чынлыкта исә, әлеге олуг хезмәтнең өчтән бере – Г. Бубиның үз сүзләре, үз иҗат җимеше. 69 битле китапның 23 нче битендә ул болай язган: «Шул ук вакытта, бу тарихтан бик күп соң, ягъни һиҗрәттән 751 елда вафат булган Ибне Каййим, шәригать дәвам ителгән кебек, иҗтиһадның дәвам ителүен сөйләгән һәм тик бу турыда *«Игълям әл-мөвәкъкыйгыйн»* исемле бер китап язган. Менә минем бу дәрәҗә-максатым шул китапны тәрҗемә итеп, милләт улларыма күрсәтү һәм, иҗтиһад бетте, дигән заманнан соңгы галимнәр һәм бөек адәмнәр ни сөйләгәннәр – шуны мәйданга кую. Хәтта иҗтиһад заманы бетмәде, дигән сүз яңа сүз түгел, бәлки иске сүз икәнлек билгеле булсын! Менә минем максатым бу. Әгәр тәкълиднең ислам һәм мөселманнар башына китергән бәлаләре минем йөрәгемне бу кадәр яндырып куырмаса, мин туп-туры бу китапның тәрҗемәсенә керешер һәм төрле китаплардан хәтеремдә калган бу озын кереш өлешне язып маташмас идем. Менә шул хәсрәтләр, менә шул ачы хакыйкатьләр минем каләмемне бу сүзләрне язарга мәҗбүр итте. Инде максатка килим дә Ибне Каййимнең сүзләрен тәрҗемә итүгә тотыныйм» (Буби 1909: 23). Димәк, хезмәтнең 23 битендә Г. Бубиның үз фикерләре, уйланулары урын алган, 23 нче биттән алып 62 нче биткә хәтле өлешендә Ибне Каййимнең *«Игълям әл-мөвәкъкыйгыйн»* әсәренең кыскача тәрҗемәсе бирелгән. 62 нче биттән 69 нчы биткә кадәр тагын Г. Буби сүзләре һәм *«Әл-мәнар»* («Маяк») журналында басылган Сәед Мөхәммәд Рашиднең *«Реформатор белән мөкаллиднең бәхәсе»* исемле хезмәтенең кыскача тәрҗемәсе китерелгән. Шулай итеп, *«Замане иҗтиһад...»* хезмәтен Г. Бубиныкы итеп санарга тулы нигез бар, Ибне Каййим китабыннан өзекләрне ул фәкать үзенең фикерен куәтләү өчен тәрҗемә иткәнлеге аның түбәндәге сүзләреннән аңлашыла: «Әгәр: “Иҗтиһад заманы үтмәде һәм билгеле бер имамның сүзенә тәкълид тиешле түгел”, – дип әйтү сез [әйткән] кебек, көферлек һәм адашу булса, бездән элек кяфер, бездән элек азгын Ибне Каййим һәм дүрт имам үзләре булырга тиешле иде, азрак инсафлык кылыгыз!» (Буби 1909: 63).

*«Замане иҗтиһад...»* әсәре түбәндәге сүзләр белән башланып китә (Бисмилладан соң): «Кешеләрнең акыллары көннән-көн үсеш тапкан һәм бу үсешнең әсәрләре дә иң надан һәм иң ахмак адәмнәрнең дә күзләрен камаштырыр дәрәҗәдә күренеп торган бер заманда бу сорауны бирү һәм “Коръәнне аңлау фәкать элекке кешеләргә махсус, алар беттеләр, Кыямәт заманына кадәр [Аллаһ] мондый адәмнәрне яңадан тудырмас” дип әйтү никадәр түбәнлек булса, аңа җавап бирү максаты белән алтыннан

кыйммәтле гомерне әрәм итү дә, хакыйкаттә, шулкадәр ахмаклык» (Буби 1909: 2). «Иҗтиһад заманы уздымы яки юкмы?» соравын бирү түбәнлек һәм аңа җавап бирү хурлык, дип санаса да, Г. Буби, хакыйкатьне ачу һәм күрсәтү өчен, бу сорауга җавап бирергә алынган. Аның фикеренчә, ислам диненең асылы – акыл һәм фикер, тәкълид исә акылга мөрәҗәгать итүне тыя, шул рәвешле, ислам бинасын җимерә, шәригатьне нигезеннән чыгара. Г. Буби, иманның максаты – хайванны бәйләгән кебек, кешене бер мәзһәбкә бәйләп кую түгел, бәлки кешеләрнең акылларын гыйлем һәм мәгърифәт дәрәҗәләреннән югары менгерү, дип санаган. Тәкълидкә ябышучыларны Г. Буби сарык көтүе белән чагыштырган. Көтүче бер сүз яисә тавыш бирсә – куйлар килә, башка бер аваз бирсә – китәләр, әмма моның килү-китү сәбәпләрен белмиләр, шуның кебек мөкаллидләр дә фәкыйһләренең сүзләренә сукырларча ияреп, һичбер нәрсә аңламыйча, диннәрен тоталар. Г. Буби юкка гына мондый чагыштыру китермәгән, чөнки Коръәннең *«Бәкарә»* сүрәсенең 171 нче аятендә хак сүзне аңларга теләмәүче кешеләр хайванга тиңләнә. *«Замане иҗтиһад...»* китабының ахыргы өлешендә автор: «Димәк, хайванлыктан һәм тәкълид дәрәҗәсеннән чыгып, кешелек һәм мәдәният дәрәҗәсенә җитү өчен, әлбәттә, акыл һәм фикерне файдаланырга кирәк», – дигән нәтиҗә чыгарган (Буби 1909: 65).

Г. Буби тәкълиднең алга киткән башка милләтләрне ислам диненә чакыруда киртә булуын ассызыклаган. Әгәр дә аларга «Менә безнең шәригатебез бу: мөҗтәһидләр тарафыннан төзелеп беткән, Коръән белән хәдисне аңлау вакыты узганлыктан, сез боларны аңламассыз! Шуның өчен сез, Коръән белән хәдискә каршы булса да, фәкыйһләр сүзен алачаксыз һәм заманыгыз файдасына муафыйкмы, түгелме – бер дә карамыйча, шуның белән гамәл кылачаксыз» (Буби 1909: 8–9) дип әйтсәк, әлбәттә, ул милләт вәкилләренең исламны кабул итүдән баш тартачаклары көн кебек ачык, чөнки, Г. Буби язганча, алар үз акыл һәм фикерләрен үтереп, элекке фәкыйһләр сүзенә баш иярге риза булмаячаклар. Әгәр динне мондый тар кысалар эчендә күрсәтсәк, ул вакытта чит милләтләрне исламга кызыктыру түгел, үз арабызда булган мәгърифәтле кешеләр дә исламнан бизәчәкләр, дип санаган ул. Шуңа күрә галим бер генә юл күргән, ул – исламны тикшереп, аны пәйгамбәр заманындагы гадилегенә кайтару һәм һәркемгә үз акылынча аңларга рөхсәт бирү. Дөрес, бу вакытта Г. Буби төрле каршылыкларның күбәюен таныган, ләкин, аның каравы, мөселманнар арасында низаглар бетәчәк, чөнки сәхабәләр һәм табигыйннар вакытында каршылыклар һичбер фанатизмсыз булган.

Г. Курсави, Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдин һ.б. татар галимнәре язып калдырганча, дүрт мәзһәбкә нигез салучылар үзләренә тәкълид кылудан катгый рәвештә тыйганнар. Г. Буби да *«Замане иҗтиһад...»* хезмәтендә бу турыда хөрмәтле имамнар Әбү Хәнифә, Шафигый, Мәлик һәм Әхмәднең сүзләрен китергән. Автор мәзһәбләргә иярүчеләрнең күплеге һәм электән үк булганлыгы белән алданмаска чакыра, чөнки, аның фикеренчә,

дөреслек күплек һәм борынгылык белән булса, башка диннәрне тотучылар һәм мәҗүсиләр дөрес юлда булыр иде.

Кайбер галимнәр иҗтиһад кылырга лаек булу өчен төрле шартлар куялар, мәсәлән, Коръәнне, меңләгән хәдисләрне, гарәп телен һ.б. камил дәрәҗәдә белү. Ләкин Г. Буби, имам Шатыйбига таянып, моның өчен гарәп гыйлемнәренең текстын һәм стилен аңлап, шәригать максатларын белү җитә, ди. Иҗтиһад кылыр өчен бөтен шәригать хөкемнәрен белүче мөҗтәһид булу шарт түгел икәнлеге хакыда Мәрҗани дә язган. Мәсәлән, галим Т. Ильяс аның *«Назурател-хакк»* китабыннан «Бер адәмнең барлык шәригать хөкемнәрен чыгаруга көче җитмәсә дә, Коръән һәм пәйгамбәрнең хәдисләрен тикшереп, кайбер хөкемнәрне чыгаруы ярый» (Ильяс 2010: 283), «Ягъни кайсы заманда гына булмасын, Кыямәт көненә кадәр һәрбер мөэмингә Коръән һәм пәйгамбәрнең хәдисе белән тотыну һәм иҗтиһад юлында булырга тиешле» (Ильяс 2010: 284) дигән фикерләрен китергән. Г. Буби да иҗтиһад дигәндә, ниндидер авыр мәсьәләләрдә хөкем чыгаруны, катлаулы сорауларга җавап эзләүне түгел, ә гади дини мәрасимнәрне үтәр алдыннан, бу эшләргә Коръәннән яки хәдисләрдән дәлил эзләүне күздә тоткан. Фәлән имам шулай әйткән, төгән мулла болай әйткән, дип кенә аларның коры сүзләренә иярмичә, гыйбадәт белән бәйле булган һәр гамәлгә үзлегеңнән Коръән һәм хәдисләрдән дәлил эзләү, Г. Буби фикеренчә, үзенә күрә иҗтиһад була. Шул рәвешле, кайсы галимнең дәлилләре Коръән-Сөннәткә яраклырак – ул шуны алырга куша. Г. Буби язганча, дини хөкемнәрне караган һәрбер акыл иясе шәригать дәлилләреннән үзе нәтиҗә чыгарырга тиеш, әгәр ул дөреслеккә ирешсә – ике саваплы, хата кылса – бер саваплы була. Әлеге сүзләрне галим мәшһүр бер хәдискә нигезләнеп әйткән. Шулай ук ул, кешенең, хөррият һәм ихтыяр хикмәтләрен саклап, хөкем чыгару белән шөгыльләнүе үз-үзен хаталы булу мөмкинлеге белән әсир итүдән хәерлерәк һәм иҗтиһадның киләчәге тәкълиднең киләчәгеннән иминрәк, дип санаган.

XIX гасырда татарлар арасында бу тәкълид шулкадәр тамыр җәйгән булган ки, әгәр бер кеше теге яки бу дини мәсьәләдә Коръән һәм хәдисләрдән җавап эзләргә чакырса, аны фанатик муллалар имансызлыкта гаепләгәннәр, хәтта олуг галимнәребез Г. Курсави һәм Ш. Мәрҗанигә дә кадимчеләр тарафыннан «кяфер» мөһере сугылган. Әгәр дә ислам тарихына күз салсак, нәкъ менә толерантлык җитмәү аркасында, мөселманнар арасында тарткалашулар һәм сугышлар чыккан, фетнәләр кубарылган, һәркем үз мәсләген таратырга һәм башкаларныкын юк итәргә керешкән, мөселманнарга бик күп зарар һәм хәсрәт китергән. Ислам өммәте, исламның башлангыч чорында бик нык алга китсә дә, соңыннан тәкълид аркасында түбәнлеккә төшкән, ләкин Г. Буби ышана ки, бер вакыт килер, тәкълид камыты мөселманнар муеныннан салыныр, алар Коръән кушкан саф иҗтиһад һәм дөрес фикерләү юлына басарлар, шул вакытта мөселманнарга рәхәт көннәр җитәр.

Г. Буби язганча, Европа халкы, тиз арада уянып, тәкълид караңгылыгыннан чыгып, иҗтиһадка, фикерләүгә тотынган һәм шул рәвешле гыйлем-мәгърифәт ягыннан югары дәрәҗәләргә ирешкән. Шул ук вакытта, ул, аларның һәр яктан үсеш кичерүе белән алданып, Европага иярүдән дә тыйган. Моны Г. Буби, бер тәкълидне ташлап, икенче тәкълидкә керү, дип санаган. Галим М. Бигиев та 1913 елда бу турыда җентекләп язган һәм бу күренешне ул яңа тәкълид дип атаган (Бигиев 2014: 336). Гомумән, Г. Буби әйткән фикерләрне шул заман татар галимнәре дә кабул кылып, үзләренең китапларында тагын да ныграк үстереп, халыкка тәкъдим иткәннәр.

Иҗтиһад проблемасын тикшергәндә, тарихчыларыбыз һәрвакыт диярлек *«Замане иҗтиһад...»* әсәрен искә алалар, аннан еш кына цитаталар китерәләр, әмма кайбер очракларда галимнең сүзләре рус теленә төгәл, сыйфатлы рәвештә тәрҗемә ителми яки нык кыскартыла. Бубилар тормыш юлын һәм эшчәнлеген өйрәнгән Р.А. Гыймазова галимнең әлеге китабына һәм иҗтиһад мәсьәләсенә багышланган мәкалә язган. Аның фикеренчә, *«Замане иҗтиһад...»* китабының 3 нче битендә «Акыллы кеше беркайчан да “Иҗтиһад заманы үттеме?” дигән сорау бирмәс. Бу – риторик сорау, һәм аңа җавап бирергә ихтыяҗ юк»[1] дип язылган икән (Гимазова 2015: 203). Чынлыкта Г. Буби алай димәгән, 3 нче һәм башка битләрдә дә андый сүзләр юк. Әсәр шуңа охшаш сүзләр белән башланып китә, ләкин алар, югарыда күрсәтелгәнчә, бөтенләй башкача яңгырый. Г. Бубиның цитаталарын китергәндә битләрен төгәл күрсәтмәү очраклары да юк түгел. Мәсәлән, «Яшәешнең хакыйкатендә Аллаһның шундый бер сөннәте һәм бер кануны бардыр ки, аңа игътибар иткән адәм мәдәниятнең иң югарысына менгән кебек, аны игътибарсыз куйган адәм дә түбәнлекнең иң түбәненә төшүдә» сүзләре 45 нче түгел (Гимазова 2015: 207), 64 нче биттә язылган (Буби 1909: 64). Шулай ук «Дөреслеккә ирешсә – ике саваплы, хата кылса – бер саваплы булыр. Димәк, кешенең хөррият һәм ихтыяр хикмәтләрен саклап, хөкем чыгару белән шөгыльләнүе үз-үзен хаталы булу мөмкинлеге белән әсир итүдән хәерлерәк» цитатасы «Дөреслеккә ирешсә – ике саваплы, хата кылса – бер саваплы булыр. Иҗтиһад тәкълидтән яхшырак»[2] рәвешендә бик кыскартылып бирелгән һәм ул 12 нче түгел (Гимазова 2015: 209–210), 14 нче биттә урын алган (Буби 1909: 14).

Тарихчы Р.М. Мөхәммәтшин, Г. Буби китабындагы кайбер җөмләләрне русчага тәрҗемә иткәндә, аларның кайбер урыннарын ни өчендер төшереп калдырган. Мәсәлән, *«Замане иҗтиһад...»* хезмәтеннән «Димәк, бу вакытта безгә алга киткән милләтләрне исламга чакыру да мөмкин булыр. Әгәр без бүген алга киткән милләтләргә: “Менә безнең шәригатебез бу: мөҗтәһидләр тарафыннан төзелеп беткән, Коръән белән

[1] «Разумный человек никогда не задаст вопрос: “Прошло ли время иджтихада?” Это вопрос риторический, и нет необходимости на него отвечать».

[2] «Если муджтахид прав – ему две награды, если ошибся – одна. Иджтихад лучше, чем таклид».

хәдисне аңлау вакыты узганлыктан, сез боларны аңламассыз! Шуның өчен сез, Коръән белән хәдискә каршы булса да, фәкыйһләр сүзен алачаксыз һәм заманыгыз файдасына муафыйкмы, түгелме – бер дә карамыйча, шуның белән гамәл кылачаксыз! Менә сезнең мөселманлыгыгыз шушында һәм адашуыгыз моның капма-каршысында", – дип әйтсәк, боларның исламга мәхәббәтләре төшәрме? Болар үз акыл һәм фикерләрен үтереп, элекке фәкыйһләр сүзенә баш иярга һәм үзләрен ахмак һәм юләр диярга риза булырлармы? Боларны Күһистаниларга, Вәлвәлиҗиләргә ничек ышандыру кирәк? Юк, болар элекке фәкыйһләр сүзе белән түгел, бәлки акылга сыешлы юл белән йөриячәкләр. Әгәр динебезне, тәкълид ияләре уйлаган кебек, болай тар бер рамка эчендә күрсәтсәк, ул вакытта кая алга киткән чит милләтләрне үзебезгә, исламга якынлаштыру; киресенчә, үз арабыздан мәгърифәтле адәмнәребезне дә (Аллаһ күрсәтмәсен) исламнан биздерәчәкбез һәм үз аягыбызга үзебез балта орачакбыз» сүзләре «Бу вакытта безгә алга киткән милләтләрне исламга чакыру мөмкин булыр. Әгәр без бүген аларга: "Менә безнең шәригатебез бу: мөҗтәһидләр тарафыннан төзелеп беткән, Коръән белән хәдисне аңлау вакыты узганлыктан, сез боларны аңламассыз! Шуның өчен сез, Коръән белән сөннәткә каршы булса да, фәкыйһләр сүзен алачаксыз һәм заманыгыз файдасына муафыйкмы, түгелме – бер дә карамыйча, шуның белән гамәл кылачаксыз! Менә сезнең мөселманлыгыгыз шушында һәм адашуыгыз моның капма-каршысында", – дип әйтсәк, боларның исламга мәхәббәтләре төшәрме? Болар үз акыл һәм фикерләрен үтереп, элекке фәкыйһләр сүзенә баш иярга һәм үзләрен ахмак һәм юләр диярга риза булырлармы? Әгәр динебезне, тәкълид ияләре уйлаган кебек, болай тар бер рам эчендә күрсәтсәк, ул вакытта кая алга киткән чит милләтләрне үзебезгә, исламга якынлаштыру; киресенчә, үз арабыздан мәгърифәтле адәмнәребезне дә (Аллаһ күрсәтмәсен) исламнан биздерәчәкбез һәм үз аягыбызга үзебез балта орачакбыз» дигән өзекне тәрҗемә иткәндә, «Боларны Күһистаниларга, Вәлвәлиҗиләргә ничек ышандыру кирәк? Юк, болар элекке фәкыйһләр сүзе белән түгел, бәлки акылга сыешлы юл белән йөриячәкләр», «...һәм үз аягыбызга үзебез балта орачакбыз» кебек кайбер җөмләләр һәм җөмлә кисәкләре төшеп калган, шулай ук «хәдис» сүзе «сунна» дип тәрҗемә ителгән (Мухаметшин 2001: 208). Р.М. Мөхәммәтшин дә бу цитатаның битләрен бутаган: ул *«Замане иҗтиһад...»* китабының 7–8 нче түгел (Мухаметшин 2001: 212), 8–9 нчы битләрендә урын алган (Буби 1909: 8–9). Әлеге тарихчы, җөмләләрне төшереп калдырганда, бер очракта гына күпнокталар куярга онытмаган: «Һәрбер фирка бер имамны иártүче [итеп] тотып, мәзһәбтә фанатизм куәтләнде... бу каршылыклар... ислам халыкларының ләгънәтенә әверелде»[3] (Мухаметшин 2001: 209). Ләкин, чынлыкта, Г. Бу-

[3] «Из-за того, что каждая группа придерживалась руководства только одного имама, усилился фанатизм в мазхабах... эти разногласия стали... проклятием народов ислама».

биның китабында «ислам халыкларының ләгънәте» («проклятие народов ислама») сүзләре бөтенләй юк.

Тарихчы Р.К. Әдһәмов та үзенең бер мәкаләсендә Г. Бубиның кайбер цитаталарын тәрҗемә иткән, тик аларның барысын да дөрес һәм төгәл дип әйтеп булмый. Мисал өчен, «Соңгы фәкыйһләрнең, Коръәндә юк [булмаган] хәез-нифас хөкемнәренә караган йөзләрчә сәхифә язган хәлдә, Коръәннең эче тулы кирәкле хөкемнәргә карамауларына сәбәп тә – менә бу тәкълид. Болар фикыһ хөкемнәренә сарыф иткән заманнарының [вакытларының] уннан берен Коръән Кәримнең бик күп җирдә әмер иткән кирәкле хөкемнәрен карауга сарыф итсәләр, бәлки мөселманнар бу кадәр наданлык һәм ахмаклыкка төшмәсләр иде» җөмләләре рус теленә «Соңгы фәкыйһләр хәез-нифас хөкемнәренә йөзләрчә сәхифә багышладылар һәм, Аллаһ мәхлукларына караган аятьләрнең күплегенә карамастан, аларны өйрәнүдән читләштеләр. Моның сәбәбе дә – нәкъ менә тәкълид. Коръәннең күп аятьләре Аллаһ мәхлуклары белән бәйле булган [табигый] кануннарны өйрәнергә чакырса да, алар фикыһ хөкемнәрен өйрәнү белән артык мавыктылар, мөселманнарның түбәнгә төшүләренең сәбәбе нәкъ менә шунда»[4] дип хаталы рәвештә тәрҗемә ителгән (Адыгамов 2015: 146).

*«Замане иҗтиһад...»* китабында Г. Курсави, Ш. Мәрҗани кебек галимнәр күтәргән иҗтиһад һәм тәкълид мәсьәләләре бик тәфсилләп аңлатылган. Аны фәкать компилятив характердагы әсәр дип санарга ярамый, чөнки хезмәтнең өчтән берендә галимнең үз сүзләре китерелгән һәм үз карашлары чагылыш тапкан. Иҗтиһад проблемасы хакында язган татар тарихчыларының барысы диярлек *«Замане иҗтиһад...»* китабына мөрәҗәгать итәләр, тик, кызганычка каршы, кайбер очракларда Г. Бубиның сүзләрен төгәл тәрҗемә итмәү күзәтелә. Һәр милләттәшебез *«Замане иҗтиһад...»* хезмәте белән үзлегеннән танышып чыга алмый. Бу инде аңлашыла да, беренчедән, ул гарәп графикасында язылган, икенчедән, иске татар телендә, ягъни хәзерге телдән шактый аерыла торган рәвештә язылган, өченчедән, гарәп-фарсы сүзләре белән чуарланган. Шуңа күрә киләчәктә аны, хәзерге татар һәм рус телләренә сыйфатлы рәвештә тәрҗемә итеп, бастыру зарур. Галимнең әлеге бибәһа хезмәте һәр татар-мөселман гаиләсе өстәлендә булырга лаек.

---

[4] «Поздние факихи посвятили сотни страниц своих трудов вопросам месячных и послеродовых кровотечений и, несмотря на многочисленность айатов, касающихся божественных творений, отстранились от их изучения. И причиной этого явился именно таклид. Они слишком увлеклись изучением правовых вопросов, хотя во многих айатах Корана присутствует призыв изучать [естественные] законы, связанные с божественными творениями, именно в этом причина упадка мусульман».

ЧЫГАНАК ҺӘМ МАТЕРИАЛЛАР

Буби Г. Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме? Казан: Милләт, 1909.

ФӘННИ ӘДӘБИЯТ

Адыгамов Р.К. Проблема иджтихада в трудах татарских богословов конца XVIII – начала XX вв. и ее влияние на современную общественно-религиозную мысль // Ислам в современном мире. 2015. Том 11, № 4. С. 139–154.

Бигиев М.Д. Избранные труды / сост. и пер. с осман. яз., введ., сн. и коммент. А. Хайрутдинова. Казань: Татар. кн. изд-во, 2014.

Гимазова Р.А. Проблема иджтихада в трудах Габдуллы Буби // Минбар. Исламские исследования. 2015. Т. 8, № 2. С. 201–215.

Ильяс Т. Фикыһ даирәсендәге хезмәтләре // Мәрҗани: фәнни-популяр җыентык. Казан: Җыен, 2010. Б. 281–337.

Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәгенең ташъязма истәлекләре. Казан: Тамга, 2008.

Мухаметшин Р.М. Религиозно-мировоззренческие искания в начале XX века // Ислам в Среднем Поволжье: история и современность. Очерки. Казань: Мастер Лайн, 2001. С. 202–212.

Хакимов Р.С. Традиционный ислам у татар. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015.

**Автор турында белешмә:** Гайнетдинов Айдар Марсиль улы – филология фәннәре кандидаты, Яңа тарих бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты (420111, Батурин ур., 7А, Казан, Россия Федерациясе); aydargm@yandex.ru

*Редакциягә керде 08.02.2022* *Кабул ителде 22.04.2022*

## О КНИГЕ Г. БУБИ «ПРОШЛО ЛИ ВРЕМЯ ИДЖТИХАДА ИЛИ НЕТ?»

***А.М. Гайнутдинов***

*Институт истории им. Ш. Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*aydargm@yandex.ru*

Перу выдающегося татарского ученого, просветителя, педагога, общественного деятеля Габдуллы Буби (1871–1922) принадлежат ценные труды по педагогике, логике, исламскому вероучению. В статье рассматривается один из опубликованных трудов Габдуллы Буби на татарском языке *«Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?»* («Прошло ли время иджтихада или нет?»), изданного в 1909 году в типографии «Миллят». Автор статьи высоко оценивает произведение Буби, обозначает вопросы, отражаемые в нем, доказывает, что данная работа не

является только лишь переводом сочинения арабского ученого Ибн Каййима *«А'лам ал-мувеккиин 'ан рабб ал-'аламин»* – треть произведения написана самим Буби. В статье приводятся случаи некачественного и неточного перевода на русский язык историками некоторых цитат из анализируемой книги.

**Ключевые слова:** Габдулла Буби, «Прошло ли время иджтихада или нет?», ислам, татарская богословская мысль, иджтихад, таклид, мазхабы, цитаты.

**Для цитирования:** Гайнутдинов А.М. Г. Бубиның «Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?» китабы хакында // Историческая этнология. 2022. Т. 7, № 1. С. 111–122. https://doi.org/10.22378/he.2022-7-1.111-122

**Сведения об авторе:** Гайнутдинов Айдар Марсилевич – кандидат филологических наук, старший научный сотрудник отдела новой истории Института истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан (420111, ул. Батурина, 7А, Казань, Российская Федерация); aydargm@yandex.ru

*Поступила 08.02.2022* *Принята к публикации 22.04.2022*

## ABOUT THE BOOK OF G. BUBI "IS THE TIME OF IJTIHAD OVER OR NOT?"

***A.M. Gainutdinov***

*Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*aydargm@yandex.ru*

The famous Tatar scientist, educator, teacher, and public figure, Gabdulla Bubi (1871–1922), wrote very valuable works on pedagogy, logic, and Islamic doctrine. The article deals with one of the main published works of Gabdulla Bubi in the Tatar language *"Zamane ijtihad munkarism, dagelme?"* ("Is the time of ijtihad over or not?"). It was published in 1909 in the Millat printing house. The author highly appreciates this work, points out the issues that are reflected in it, proves that it is not only a translation of the work of the Arab scholar Ibn Qayyim "*I'lam al-Muwaqqi'in 'an Rabb al-'Alamin*", because one third of the work is written by G. Bubi. The article also cites cases of low-quality and inaccurate translation into Russian by historians of some quotations from the book "Is the time of ijtihad over or not?".

**Keywords:** Gabdulla Bubi, "Is the time of ijtihad over or not?", Islam, Tatar theological thought, ijtihad, taqlid, mazhabs, quotes.

**For citation:** Gainutdinov A.M. G. Bubinyñ «Zamane idzhtihad mönkarizmy, dägel'me?» kitaby hakynda [About the book of G. Bubi "Is the time of ijtihad over or not?"]. *Istoricheskaya etnologiya*, 2022, vol. 7, no. 1, pp. 111–122. https://doi.org/10.22378/he.2022-7-1.111-122 (In Tatar)

## REFERENCES

Adygamov R.K. Problema idzhtihada v trudakh tatarskikh bogoslovov kontsa XVIII–nachala XX vv. i yeye vliyaniye na sovremennuyu obshchestvenno-religioznuyu mysl [The problem of ijtihad in the works of Tatar theologians of the late 18th – early 20th centuries. and its influence on modern socio-religious thought]. *Islam in the modern world*, 2015, vol. 11, no. 4, pp. 139–154. (In Russian).

Bigiyev M.J. Izbrannyye trudy [Selected works]. Kazan: Tatar. kn. izd-vo, 2014. (In Russian).

Bubi G. Proshlo li vremya idzhtihada [Has the time for ijtihad passed?]. Kazan: Millat, 1909. (In Russian).

Gimazova R.A. Problema idzhtikhada v trudakh Gabdully Bubi [The Problem of Ijtihad in the Works of Gabdullah Bubi]. Minbar. Islamic Studies, 2015, vol. 8, no. 2, pp. 201–215. (In Russian).

Ilyas T. Fiqyh dairäsendäge hezmätläre [His works in the field of jurisprudence]. *Marjani: popular science collection*. Kazan: Jyen, 2010, pp. 281–337. (In Tatar).

Mardanov R.F., Hadiev I.G. Agerje tobägenen tashyazma istälekläre [Epigraphic monuments of the Agryz region]. Kazan: Tamga, 2008. (In Tatar).

Mukhametshin R.M. Religiozno-mirovozzrencheskiye iskaniya v nachale XX veka [Religious and ideological searches at the beginning of the 20th century]. *Islam in the Middle Volga region: history and modernity. Essays*. Kazan: Master line, 2001, pp. 202–212. (In Russian).

Khakimov R.S. Traditsionnyi islam u tatar [Traditional Islam of the Tatars]. Kazan: Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences, 2015. (In Russian).


**About the author:** Aidar M. Gainutdinov, Cand. Sc. (Philology), Senior Research Fellow of the Department of Modern History, Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7A Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); aydargm@yandex.ru.

*Received February 8, 2022* *Accepted for publication April 22, 2022*

# Документы и материалы

УДК 929

## «КАЖДОЕ ИХ ДЕЛО – ПРОТИВ КОРАНА И ШАРИАТА, А ЗНАЧИТ, И ПРОТИВ ПРАВИТЕЛЬСТВА». О СУДЕБНОМ ДЕЛЕ БРАТЬЕВ БУБИ

***Л.Ш. Давлет***

*Институт Татарской энциклопедии и регионоведения*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*tafkilevna@mail.ru*

28 мая 1912 г. в городе Сарапуле Вятской губернии прошло судебное заседание по делу братьев Буби. Репортаж о нем был опубликован в газете *«Юлдуз»* 27 мая, 31 мая и 3 июня 1912 г., а на кириллице – в сборнике *«Бертуган Бубыйлар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе»* (1999). Автор осуществил перевод этого материала на русский язык. Во вступлении он анализирует характер репортажа: журналист высказывается весьма благожелательно по отношению к братьям-просветителям и едко высмеивает печально известного своими нападками на джадидов Ишмиишана. Текст репортажа позволяет почувствовать настроение либеральной части татарского общества того времени, отношение русского населения края к проблемам соседей-татар.

**Ключевые слова:** Габдулла и Губайдулла Нигматуллины-Буби, медресе Иж-Буби, дело братьев Буби, газета *«Юлдуз»*.

**Для цитирования:** Давлет Л.Ш. «Каждое их дело – против Корана и шариата, а значит, и против правительства». О судебном деле братьев Буби // Историческая этнология. 2022. Т. 7, № 1. С. 123–135. https://doi.org/10.22378/he.2022-7-1.123-135

2 февраля 1911 г. руководители медресе Иж-Буби – братья Габдулла и Губайдулла Нигматуллины-Буби – были арестованы и заключены в Сарапульскую тюрьму. Они обвинялись в панисламизме, участии в работе нелегального национального общества «Младотатары», распространении среди шакирдов антирусских и антиправительственных идей, хранении панисламистской литературы. Суд над братьями состоялся в городе Сарапуле 28 мая 1912 г. Защитниками Буби выступили адвокаты И.А. Ахтямов, В.А. Маклаков и другие, экспертами восточных книг – П.К. Жузе и Н.Ф. Катанов. В ходе судебного заседания предъявленные обвинения бы-

ли сняты, однако по политическим соображениям братья Буби были приговорены к нескольким месяцам заключения: Губайдулла был освобожден в конце 1912 г., Габдулла – в начале 1913 г.

За судебным процессом над братьями Буби следили две татарские газеты: *«Юлдуз»* («Звезда») – общественно-политическое издание демократического толка – и *«Баянельхак»* («Глашатай истины») – издание клерикально-консервативного характера. Оба издания в дни судебного заседания отправили в город Сарапул собственных корреспондентов. Ниже приводится небольшой репортаж, опубликованный в газете *«Юлдуз»* 27 мая, 31 мая и 3 июня 1912 г. и переведенный на русский язык. Перевод сделан по изданию *«Бертуган Бубыйлар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе»* (Казан, 1999).

Репортаж написан очень благожелательно по отношению к братьям-просветителям, при этом журналист едко высмеивает печально известного своими нападками на джадидов Ишми-ишана, иногда доходя до откровенной издевки. По тексту прочитывается настроение либеральной части татарского общества того времени: здесь есть и надежды улучшить жизнь народа своим трудом, и апелляция к широкой народной поддержке, и стремление назначить главного виноватого – вполне осязаемого и поэтому уязвимого врага. Раскрывается отношение русского населения края к проблемам своих соседей-татар.

**О деле Буби**

(от нашего собственного корреспондента)

Правые газеты радостно пишут об аресте братьев Буби: «Российские татары левого толка распространяли среди мусульман идеи панисламизма и пантюркизма. Но в последние годы их цели стали известны правительству. По этой причине во многих местах прошли обыски, и было конфисковано множество записей. В Сарапульском уезде были арестованы учителя – братья Буби, главные распространители идей панисламизма среди местного населения. Теперь нужно изгнать эту заразу из других мест», – и другие такие же немыслимые слова, пытаясь угодить правительству. Но, по мнению сведущих людей, там нет никакого дела, заслуживающего внимания. Так как среди российских мусульман не было и нет идей панисламизма, да и не будет никогда. Бессмысленно тратить жизнь на такие пустые разговоры – это понимает каждый разумный человек. Может, некоторые люди не согласятся со мной, спросят: «Почему же тогда арестованы братья Буби?». Ответ таков: это личное дело. К тому же пока доподлинно не известно, панисламисты они или нет. Суд откроет истину.

Когда в России началась революция[1], левые идеи нашли здесь множество последователей. В то время и придерживающиеся умеренных взглядов стали поддерживать левых. Может, в те времена и братья Буби напи-

[1] Имеется в виду революция 1905–1907 гг.

сали что-то, что не совсем вписывалось в закон. Но это нужно рассматривать как веяние времени и не больше.

В последние годы во многих местах России среди мусульман прошли обыски, было конфисковано множество документов, книг. Но не было найдено ни одной крамольной книги и документа. Поэтому книги и документы, после того как их прочли чиновники, владеющие татарским и арабским языками, были возвращены владельцам. Если бы действительно была вина, приписываемая правыми газетами, где-то нашлись бы тетради с записями пожертвований для турецкого флота или другие документы с печатью комитета *«Иттихад ва таракки»*. Но неизвестно ни об одной такой находке. Правда, в последние годы некоторые муллы были отстранены от службы с обвинением в сборе пожертвований в пользу турецкого флота. Но причина этого – лишь доносы. Некоторые муллы посредством доносов просто расправились с неугодными им имамами. Некоторые чиновники предпочли истолковать эти доносы как проявление патриотизма и дали ход делу. Таким образом, лишь по причине личных распрей многие имамы лишились своих мест, а семьи остались без средств для жизни…

Если бы суть этих дел не стала известна правительству, доносы и лишения службы так и продолжались бы. Наконец, чиновники поняли истинную причину этих доносов, перестали обращать внимание на доносчиков. В некоторых местах сами доносчики стали привлекаться к суду. Так как по российским законам никаким способом нельзя угнетать человека.

Я спросил у одного уважаемого имама о том, как возник этот вопрос о сборе денег для турецкого флота. Он посетовал на невнимательность Духовного Собрания: «Духовное Собрание прислало нам циркуляр о запрете на сбор средств для турецкого флота, но написан он был настолько путано и витиевато, что его не поняли не только те муллы, которые не знали русского языка, но даже те, кто знал. Может, некоторые имамы поняли, что Духовное Собрание велит собирать средства? Это, должно быть, правда, так как до распространения этого циркуляра имамы ничего не знали об этом. В правых газетах писали: „Мусульмане Индии собирают пожертвования в пользу турецкого флота; наверное, и российские мусульмане собирают“, поэтому Министерство внутренних дел обратило внимание к этому вопросу».

Мы прибыли в Сарапул в 11 часов утра 26 мая. Я хотел расспросить на пароходе о деле братьев Буби, но это оказалось невозможным. Не было никого, кто бы обратил внимание на это дело. Лишь один мусульманин из Троицка рассказал о том, что Ишми мулла[2] сильно боялся ехать в Сара-

---

[2] Динмухамметов Ишмухаммет (Ишми-ишан) (1842–1919), религиозный деятель, представитель кадимизма. Резко выступал против джадидизма; протестовал против введения нового звукового метода обучения грамоте, который, как он считал, глубоко противоречил нормам ислама, т. к. заимствован у «неверных»; призывал к активному противодействию джадидам, не исключая использования различного рода репрессий и насилия.

пул: «Он даже просил одного солдата для охраны. Но я не знаю, дали ему охрану или нет».

